РИЗЫК КАДЕРЕ

Россиядә ел саен 17 млн тонна азык-төлек чүплеккә ташлана

> 7

БЕТМӘСЕН «ӨМЕТ»

Яңа Кенәр тернәкләндерү үзәген ник япканнар?

> 15

ЛӘЙСӘН МӘХМҮТОВА:

«Иң яратмаган нәрсә – акча эзләү»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 108 (28881) | Җомга | 29 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

АГУЛЫ БАЛ

БАЛ КОРТЛАРЫ БЫЕЛ ДА КЫРЫЛА

Умартачылар кабаттан зар елый, чаң кага: быел да республикада бал кортлары кырыла. Зыян күрүчеләр йөзгә җитте, тик күпчелеге, мәшәкатеннән куркып, проблеманы әйтмәү ягында. Саба, Питрәч, Биектау, Арча, Әлмәт, Лениногорск районнарында хәлләр аеруча катлаулы. Умартачылар белән аграрийлар ни сәбәпле һаман да уртак фикергә килә алмый? Ни өчен узган еллардагы вакыйгалардан сабак алынмый? Умартачылар нәрсә тәкъдим итә? «ВТ» хәбәрчесе әлеге четерекле мәсьәләдә алтын урталыкны табарга тырышты.

> 6

Ишетми калмагыз

Россия Хөкүмәте, кереме яшәү минимумыннан кимрәк булган эшләмәүче пенсионерларга ярдәм итү өчен, төбәкләргә 10 миллиард сумнан артыграк акча бирәчәк. Субсидияне алар пенсиягә өстәмә сыйфатында алачак.

Билгеле булганча, 1 июньнән Россия Президенты кушуы буенча яшәү минимумы күләме 10 процентка артырылды. Бу исә төбәкләр бюджетыннан акчаны күбрәк тотуга, аны киеренкеләндерүгә китерде. Федераль үзәк субсидияләре әлеге чыгымнарны каплау һәм 1 миллионнан артыграк кешегә өстәмә түләү мөмкинлеге бирәчәк. Шулай итеп, эшләмәүче пенсионерларның пенсиясе аена уртача 19 мең сумнан артып китәчәк.

Мәскәү – Түбән Новгород – Казан М12 түләүле автомобиль магистрален, Чаллы һәм Түбән Кама урау юлын төзүче оешмалар Татарстан юлларын үз хисабына төзекләндерәчәк. Республика транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов шулай дип белдерде. «Зур автомобиль юлларын салуда, төзелеш материалларын ташу өчен, җирле юллардан файдаланыла. Ә алар, авыр йөкләргә исәпләнмәгәнлектән, тиз туза, сафтан чыга. Шуңа күрә төзелеш оешмалары җирле юлларны да яңартачак», – диде ул «туры элемтә» вакытында.

Министр әйтүенчә, М12 юлын төзүдә 252 чакрымнан артыграк озынлыкта җирле юллардан файдаланыла. Шәле – Баулы өлешен төзүдә 150 чакрым чамасы озынлыктагы җирле юллар җәлеп ителгән. Ә Чаллы һәм Түбән Кама урау юлын салуда 60 чакрымлы республика юлы «катнаша». Министр басым ясап әйткәнчә, магистральне төзеп бетергәндә, калган барлык юллар да капиталь төзекләндереләчәк.

Апрель – июнь чорында Татарстан банкларына 148 ялган акчаның килеп керүе ачыкланган. Бу – беренче кварталдагыга караганда 6,7 процентка кимрәк. Россия банкының Татарстандагы бүлеге матбугат хезмәте хәбәренә караганда, ялган купюраларның күпчелеге – биш меңлекләр. Аларның өлеше барлык «фальшивка»ның 92 процентын (136 данә – беренче кварталдагыдан 58 данәгә артыграк) тәшкил итә.

Безнең акчаның чынлыгын махсус җиһаздан башка гына да тикшерергә мөмкин. Әйтик, яктыга куеп караганда, биш меңлектә «5000» саны һәм Муравьев-Амурский портреты рәвешендәге су билгеләре күренә.

Беренче яртыеллыкта Татарстанда энтеровирус (тән температурасы күтәрелә, эч китә, укшыта) йоктыруның 30 очрагы теркәлгән. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе хәбәр иткәнчә, узган елның шушы ук чорындагы белән чагыштырганда бу өч тапкыр күбрәк. Быел гыйнвар – июнь айлары арасында энтеровирус белән бер яшьтән ике яшькә кадәрге сабыйлар ешрак чирләгән. Белгечләр аңлатуынча, энтеровирус пычрак су, көнкүреш әйберләре аша һәм чирле кеше төчкергәндә-йөткергәндә эзрә. Инфекция йоктырмас өчен кулларны ешрак юарга, махсус җиһазланылмаган комлыклар һәм бассейннарда су коенмаска киңәш итәләр.

Районнарда ни хәлләр?

Апас

Район халкы «Әбиләр кайгыртуы» акциясенә кушылды. Өлкәннәр, волонтерлар һәм битараф булмаган райондашлар бәйләгән бияләй, оекбаш, шарф, свитерлар һәм башка кирәк-яраклар Донецк һәм Луганск халкы өчен «Бердәм Россия»нең гуманитар ярдәм үзәкләренә китәчәк һәм мохтаҗларга тапшырылачак. Кызыл Тау авылында яшәүче 95 яшьлек Назирә әби Кәримова 5 пар оекбаш бәйләп җибәргән. («Апас-информ»)

Югары Ослан

Район үзәк хастаханәсендә дәваланучы дин кардәшләребез өчен намаз уку бүлмәсе эшли башлады. Берничә көн элек шул ук хастаханәдә православ динен тотучылар өчен дә гыйбадәт бүлмәсе ачылган иде. Әлеге бүлмәләр Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм республика митрополиясе арасында хезмәттәшлек турында өчьяклы килешү кысасында булдырылды. Намаз уку бүлмәсе төзекләндерелгән, келәм җәелгән һәм бүлмә суык вакытта җылытыла. Хәзерге вакытта республиканың барлык район хастаханәләрендә дә диярлек намаз уку бүлмәләре бар. Моннан тыш, намаз уку өчен 2 бүлмә Чаллыдагы Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсендә эшли. Казанда МКДЦ, РКБ, ДРКБ, Республика клиник онкология диспансеры, 7 нче поликлиникада гыйбадәт кылу урыннары бар. (Татарстан Диния нәзарәте)

Азнакай

Актүбә бистәсенең ат-спорт мәктәбендә ат өстендә көрәш ярышы үтте. Татарстан чемпионатына Кукмара, Алабуга, Әлмәт, Бөгелмә, Азнакай, Лениногорск, Саба, Түбән Камадан көрәшчеләр җыелды. Халык телендә «Аударыш» дип аталган ярышларда 50дән артык спортчы катнашты. Ярышларда катнашучылар да татар атларында көрәште. Аларны әлеге ярышны оештыручыларның берсе Фәрит Нәбиуллин Лениногорскидан алып килгән. Көрәшнең кагыйдәсе шундый: көндәшеңнең билбавыннан гына тартырга ярый, кем дә кем аттан җиргә беренче булып егылып төшә, шул җиңелә. («Маяк»)

Түбән Кама

Түбән Кама шәһәре 2021 ел нәтиҗәләре буенча Россиянең акыллы шәһәрләре рейтингының «Зур шәһәрләр» категориясендә 6 нчы урынны алды. Россия Төзелеш министрлыгы шәһәрләрнең IQ индексын бастырып чыгарды. Нәтиҗәне шәһәр идарәсе, акыллы ТКХ, шәһәр мохите өчен инновацияләр, акыллы шәһәр транспорты, иҗтимагый һәм экологик куркынычсызлыкның интеллектуаль системалары, туризм һәм хезмәт күрсәтү, социаль хезмәтләрнең интеллектуаль системалары, икътисад һәм инвестклимат, шулай ук элемтә челтәре инфраструктурасы үсешләрендә 47 күрсәткеч буенча ясаганнар. Түбән Кама халкы 100 меңнән 250 меңгә кадәр кешесе булган шәһәрләр арасында 81,55 балл җыйган. (e-nkama.ru)

tatarstan.ru

«Сәләт»кә өмет

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Сәләт» халыкара уку-укыту форумы катнашучылары белән очрашты. Гадәттәгечә, республика җитәкчесе аланнар эшчәнлеге белән танышып, сәлкешләрнең хәлен белеште.

Хәзерге көндә «Сәләт»нең бишенче сменасы бара. Барлыгы алты смена оештырылачак. 27–31 июльдә уза торган смена мәгълүмати технологияләргә багышланган. Биредә 1077 бала ял итә. Гомумән, алты смена кысасында Биләр җире 6300 сәлкешне кабул итәр дип көтелә.

Рөстәм Миңнеханов җирле видеостудиядә узган әңгәмә вакытында республикада татар телен, милли гореф-гадәтне һәм мәдәниятне саклау һәм үстерүгә зур игътибар бирелүе турында сөйләде.

– Биредә зур үзгәрешләр булган. Соңгы берничә ел эчендә «Сәләт» бик нык үсте, – диде ул сәлкешләр белән очрашкач. – Быел «Адымнар» комплексында «Сәләт» класслары булдырылды, «Сәләт» базасын Кырымда ачтык. Быел Биләрдә 6 смена үтә. Россиянең төрле төбәкләреннән, Татарстанның барлык районнарыннан меңләгән бала, яшьләр бергә җыела. Сезнең өчен киң мөмкинлекләр ачыла. «Сәләт» туган телне һәм мәдәниятне саклау һәм үстерү эшендә дә алдынгы сафларда тора. Бу шулай булды һәм булачак та. Шушы җаваплылыкны гел истә тотарсыз дип ышанам. Без сезгә зур өметләр белән карыйбыз, – диде Президент.

Татарстанның яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов әйтүенчә, «Сәләт» – Россия һәм Татарстанның төрле төбәкләреннән җыелган меңләгән бала өчен мөмкинлекләр мохите. «Форум елдан-ел камилләшә. Палаткалы лагерьдан ул инде тулы канлы белем бирү системасына әверелде», – диде министр.

«Сәләт» яшьләр үзәге директоры Айгөл Габдрахманова форумның эшчәнлеге белән таныштырды. «Форум буларак 2012 елдан бирле эшлибез. 26 ел дәвамында без Биләр җиренә кайтабыз. Киләсе елга «Сәләт»нең 30 еллыгын билгеләп үтәбез», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов:

«Баласы өчен әти-әни җавап тота»

Нәтиҗә

Татарстанның суд приставлары әҗәтлеләрдән 2022 елның беренче яртысында 6,8 млрд сум бурычларын түләттергән. Шуның 291 млн сумы әти-әнисе алимент түләмичә йөргән сабыйларга кайтарылып бирелгән. Бу хакта Казан Ратушасында узган Федераль суд приставлары хезмәте коллегиясенең күчмә утырышында әйттеләр.

Утырышны Россия Суд приставлары федераль хезмәте директоры – Баш суд приставы Дмитрий Аристов алып барды. Сүз башында ул илнең төрле төбәкләреннән килгән суд приставлары Казанда дүрт көнлек эшлекле сәфәрдә булуын әйтте. Алар эш турында гына сөйләшеп калмаган, башкала белән танышкан. Тарихи урыннарны барлаганнар. Казаныбызны ошатып китүләрен яшермиләр. Дмитрий Аристов кунакчыллык өчен республика җитәкчеләренә рәхмәтен җиткереп кенә калмады, республикадагы дәүләт органнарының суд приставлары белән хезмәттәшлегенә югары бәя бирде.

– Моңа Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе эшчәнлеге ачык дәлил булып тора ала. Идарә үз эшенең нәтиҗәләре белән республикада социаль-икътисади мәсьәләләрне хәл итүгә зур өлеш кертә. Быелның 6 аенда гына да суд приставлары һәм башкаручылары илнең бюджет системасына 2 млрд сумга якын акча түләттергән. Аларның 1,5 миллиардтан артыгы республика бюджетына кергән, – ди Дмитрий Аристов. – Татарстанда түләттерелгән административ штрафларның 60 проценттан артыгы – ЮХИДИнеке. Ярты ел эчендә суд приставлары машина йөртүчеләрдән 240 млн сум бурыч түләттергән. Хезмәт хакын түләмәгән оешмалардан – 61 миллион сум, торак-коммуналь хезмәтләр өчен 324 миллион сум бурычларын кайтартып алганнар.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та суд приставларының эшчәнлегенә уңай бәя бирә.

– Суд приставлары хезмәте республикабызда яшәүчеләр һәм Россия халкын борчыган мәсьәләләрне хәл итүдә алдынгы урынны били. Аларның эше һәркемгә шәхсән якын килүдән гыйбарәт, – ди Президент. – Суд приставлары хезмәте кертүче яңалыклар да уңай нәтиҗә бирә. Әйтик, узган ел республикада суд приставлары хезмәте һәм гомуми юрисдикция судлары арасында башкарма һәм процессуаль документлар алмашу буенча электрон документ әйләнеше кертелде. Әлеге проект эшли башлаганнан бирле Татарстан судлары суд приставларына 73 меңнән артык башкарма документ җибәргән. Шуларның 40 меңе быел җибәрелгән. Хәзерге вакытта мондый хезмәттәшлек җәмәгать судьялары белән оештырыла.

Рөстәм Миңнеханов алиментларны түләттерү турындагы производстволарның елдан-ел артуын да әйтеп үтте. Ә менә хезмәт хакын түләттерү, социаль якланмаган гражданнарга торак бирү, шулай ук дару препаратлары белән тәэмин итү буенча да хәл тотрыклы. «Мобиль эзләү» кушымтасының яхшы нәтиҗәләр бирүе хакында да сөйләде. Бурычы булган йөзләгән кешенең машинасы кулга алынган.

Очрашуда суд приставлары хакында гына түгел, аларга йомышы төшкән кешеләр турында да сөйләштеләр. Бүлекчәләрдә халык өчен уңайлы шартлар тудырылган. Быел 9 суд приставлары бүлекчәсендә төзекләндерү эшләре тәмамланган, тагын өчесендә эшләр дәвам итә икән әле.

Татарстан Президенты суд приставларының куркынычсызлыгын тәэмин итү турында да сөйләде.

– Республикада суд биналарының куркынычсызлыгы һәм террористик юнәлештәге җинаятьчел гамәлләрне кисәтү системасы эшли. Барлык судлар һәм җәмәгать судьяларының суд участоклары заманча техник саклау чаралары белән тәэмин ителгән. Бу юнәлештә эш дәвам итәчәк, – диде ул.

Татарстан Президенты журналистлар белән сөйләшкәндә, алимент түләмәүче әти-әниләр мәсьәләсенә тукталды.

– Ата-аналар үз баласы өчен җаваплы. Тормышта төрле хәлләр була, гаилә таркала. Кызганыч, аерылышкач, барлык әти-әниләр дә балалары хакында уйламый. Кагыйдә буларак, алиментларны ир-ат түләргә тиеш була. Ир-ат бала алдында бурычлы булып кала. Ул бурычын үтәргә тиеш, – ди Президент. – Әлеге сабыйларны дәүләт кайгырта. Суд приставларына алиментларны түләтү буенча башкарылган эшләре өчен рәхмәт әйтәсем килә. Бу – безнең гражданнарны яклау, балалар хокукларын тәэмин итүебез. Алты айда баласына алимент буенча түләттерелгән 291 миллион сум акча тулы булмаган гаиләләргә килеп ирешкән дигән сүз бит инде ул. Алар өчен 100 сум да зур акча. Бу эшләр киләчәктә дә контрольдә булсын.

Федераль суд приставларының эшчәнлегенә күз салсак, Дмитрий Аристов сүзләренә караганда, алар быелның алты аенда бурычлылардан 515 млрд сум акча түләттергән. 11 миллионнан артык бурычлы кешегә карата Россиядән чыгуны вакытлыча чикләү турында карар кабул ителгән. 339 мең башкарма производство кысасында бурычлыларның транспорт чаралары тоткарланган.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

«Нәфис Косметикс» акционер җәмгыяте – М. Вахитов исемендәге Казан химия комбинатына (Крестовниковларның элеккеге 1 номерлы сабын һәм шәм заводы) «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме бирү турында

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү яулауга зур өлеш керткәнә, Бөек Ватан сугышы елларында хәрби һәм граждан продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин иткән сәнәгать предприятиесе хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт каһарманлыгы һәм фидакарьлеге өчен «Нәфис Косметикс» акционер җәмгыяте – М. Вахитов исемендәге Казан химия комбинатына (Крестовниковларның элеккеге 1 номерлы сабын һәм шәм заводы) «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме бирергә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н.Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 28 июль
№ ПУ-509

ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ!

ИГЕНЧЕЛӘР УРАККА ТӨШТЕ

Татарстан игенчеләре урып-җыю эшләренә кереште. Беренчеләр исемлегендә – Зәй, Буа, Яшел Үзән, Апас, Алексеевск, Азнакай, Чүпрәле, Актаныш районнары. Берничә районда шепкән (рыжик) – май культурасын җыя башлаганнар, шулай ук көзге арыш, бодай, арпа суктыручылар да бар. Республика Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, әлегә 563 гектар мәйданнан 2770 тонна көзге бодай суктырылган.

vk.com

Беренчеләрдән булып уракка төшүчеләр арасында зәйлеләр дә бар. Бу атнада кыр комбайннары бөртекле культуралар җыярга керешкән. Районның авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе Фәргать Камалиев әйтүенчә, Зәй игенчеләренә 14 мең гектар бодай, 14 мең гектар арпа, алты мең гектар язгы бодай җыеп аласы булачак. Шулай ук алар шепкән һәм борчак суктырырга керешә.

– Барысы да эшкә әзер. Кырга 44 комбайн чыкты. Быел уңыш мул, шунлыктан җыеп алырга җиңел булмаячак. Вакытны да, көчне дә юкка сарыф итәргә ярамас, урып-җыю чорында һәр минут кадерле. Бу – зур хезмәт, – диде ул.

Әлегә суктырылган мәйданнар зурлыгы буенча Яшел Үзән аграрийлары сынатмый. Районның авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе Таһир Җиһаншин әйтүенчә, кыр кораблары 23 июльдә көзге бодайга чыкканнар. Моннан тыш шепкән культурасын суктыралар.

– Узган ел белән чагыштырганда, уңыш әйбәт. Тик иң кирәкле вакытта безнең районда яңгыр булмады, шуңа күрә уңыш көтелгәннән бераз кимрәк күренә. Ләкин әле вакыт бар, сынатмабыз, дип уйлыйм. Уңыш гектарыннан 30 центнердан артык чыга. Иң мөһиме – булган уңышны җыеп алырга матур көннәр булсын, дип телибез. Булганның бәрәкәте булсын, – диде ул.

Игенчеләр сүзләре буенча, быел яхшы уңыш алыр өчен барлык шартлар да бар. Республика Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының булек җитәкчесе Ирек Садыйков әйтүенчә, кырларда ашлык формалашу яхшы бара.

– Быел яңгырлар күп яуды. Башка еллар белән чагыштырганда, явым-төшемнең уртача нормасы күбрәк. Ә инде майның салкын килүе корткычлар артуны тоткарлап торды, – ди ул.

Синоптиклар да кыр эшләре өчен җылы һава торышы уңай булуын әйтә. Нәкъ менә шундый һава дымлылыгы 14 процент булган сыйфатлы ашлык җыярга мөмкинлек бирә, ди алар.

КИЕМЕҢӘ КАРАП КАРШЫ АЛСЫННАР

kodfest.ru

Барыбыз да бертөрле мохиттә яшәп, бертөрле киенеп, үзенчәлегебезне югалтабыз түгелме? Милли киемне көндәлек тормышка ничек кайтарырга? Милли продукция җитештерүчеләргә ничек ярдәм итәргә? Бу һәм башка мәсьәләләр турында 2–7 августта Казанда узачак «Стиль жизни – культурный код» фестивалендә сөйләшәчәкләр.

Билгеле, мондый фикер алышу – чараның бер өлеше генә. Оештыручыларның сүзләренә караганда, фестиваль программасында «Хәзинә» галереясында тәкъдим ителәчәк декоратив-гамәли сәнгать күргәзмәсе (2–14 август), халыкара конференция (2–7 август, Казан Кремле), милли продукция ярминкәсе (2–7 август, Камал театры каршындагы мәйданчык), төрле дизайнерларның милли коллекцияләрен тәкъдим итү кичәләре (2–5 август, Казан Кремле), этномузыка фестивале дә (2–7 август, Казан Кремле) каралган.

– Милли киемнәребез көндәлек тормышка кайта башлады. Мин моңа бик сөенәм, – диде Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова фестивальгә багышланган матбугат очрашуында. – Глобальләшү аркасында без үзенчәлегебезне югалттык. Әйтик, моннан ике гасыр элек кешеләр бер-берсен киемнәренә карап та аңлаганнар. Киемнең үз теле булган. Киеменә карап каршы алалар, дип юкка гына әйтелмәгән бит. Кеше өс киемен матди хәленә, нинди нәсел вәкиле булуына, гаилә хәленә карап сайлаган. Ә бүген без йөзсез кебек. Ягъни без яши торган мохит һәм тышкы кыяфәтебез берни турында сөйләми диярлек.

Министр әйтүенчә, милли киемне бүгенге шартларга туры китерү һәм яңа актуаль итү – мөһим бурычларның берсе. Бу фикерне «Бюро Бану» бренды баш дизайнеры Элара Шәйхи дәвам итте:

– Без этник костюмнарның тарихы турында гына сөйләп калмыйча, аларны бүгенге шартларга, модага ничек яраштырып булганын күрсәтергә телибез. Алай гына да түгел, бу фестиваль – төрле төбәкләрдән, илләрдән килгән дизайнерлар өчен очрашу, тәҗрибә алмашу урыны да. Нәтиҗәдә фестивальне килеп күргән кешеләрнең этник тенденцияләргә карашы үзгәрер дип өметләнәбез, – дип сөйләде ул.

Сүз уңаеннан, «Стиль жизни – культурный код» фестивале инде икенче мәртәбә уздырыла. Быел Татарстан башкаласына Россиянең 24 төбәгеннән һәм Кыргызстан, Төрекмәнстан, Казахстан, Таҗикстан, Әзәрбайҗан, Үзбәкстаннан барлыгы 30 дизайнер килер дип көтелә.

Быел фестивальдә эшлекле программа да каралган. Белгечләр мәдәни код мәсьәләләре турында фикер алышачак. Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков фикеренчә, халыкның бердәйлеге фольклор әсәрләрдә саклана. «Фольклорны үзгәртеп булмый. Аны халык тудырган. Әйтик, дастаннарны гына алыйк. Игътибар белән укысаң, анализларга сәләтле булсаң, аларда халыкның чын тормышы сурәтләнгән бит», – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Өзелгән юл

Быелның 6 аенда Татарстан юлларында 127 кешенең гомере өзелгән, тагын 1821е имгәнгән. Республикада барлыгы 1460 авария килеп чыккан. Аварияләр һәм имгәнүчеләр узган елгыдан азрак булса да, һәлак булганнар саны 9га күбрәк. Бу мәгълүматны юл хәрәкәте иминлеге буенча Татарстанның Хөкүмәт комиссиясендә җиткерделәр.

Кеше үлеменә китергән аварияләрнең 76 проценты бәрелешү һәм җәяүлеләрне таптау аркасында килеп чыккан. Һәлак булган һәр дүрт кешенең берсе машина астына үз игътибарсызлыгы аркасында барып кергән. Җәяүлеләрне таптау очраклары 14 районда арткан.

Комиссия утырышында махсус хезмәтләрнең авария булган урынга килеп җиту вакытын киметү, куркыныч участокларда иминлекне арттыру, мәктәп автобуслары турында сөйләштеләр. Соңгы 5 елдагы саннар исә аварияләр иң күп була торган чорның 3 нче кварталга, ягъни июль – сентябрь айларына туры килгәнен күрсәтә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Очрашу

Беркөнне Казанның Восход урамында хатынның теш табибыннан чыкканын көтеп утырдым. Бу урамда инде ай буе юлны рәтлиләр, асфальт җәяләр. Ярый әле машина куяр өчен алдан ук урын әзерләп куйганнар.

Көтеп утырам шулай. Кинәт артымда ук эвакуация машинасы килеп туктады. Юл кагыйдәләрен бозмадым шикелле, шулай да күңелгә шик кереп, машинадан чыктым. Баксаң, асфальт тигезләүче катокны алып китәргә килгән икән. Кызыксынып карап торуымны күргәч, шофер егет елмаеп кул болгады, мин дә сәламләдем: «Ну җәлт тә эшлисез инде!» – дип куйдым.

– Тырышабыз.

– Безнең як егетләре түгелдер?

Таныш түгел кешеләр белән сөйләшә башлаганда, гадәттә, шулай дип шаяртам һәм шаяртуларым еш кына дөрескә чыга.

– Сез үзегез кайсы якныкы соң, абый?

– Арчаныкы.

– Мин дә Арчаныкы бит.

– Кайсы авылдан?

– Утар Атыдан.

– Күрше авыл егете икәнең бит, мин – Субаш Атыдан.

Яшь аермабыз шактый булса да, уртак танышлар күп иде безнең. Шактый вакыт сөйләшеп тордык. Аның да китәсе килми, минем дә ашыгасы җир юк. Ни гаҗәп, күңелдә ниндидер бер рәхәтлек хисе иде. Казанның бер урамында очраклы рәвештә күрше авыл егете белән очрашу һавада очып йөргән ике мамыкның бер-беренә килеп бәрелүе кебек тоелды.

Минем белән андый хәлләр еш була. Гомумән, кеше белән аралашырга бик яратам, еш кына бөтенләй таныш булмаган кешегә сүз катам. Мине якыннан белмәүчеләр бу ычкынган икән дип тә уйларга мөмкин. Очраклы танышлар белән тәмам дуслашып киткән чаклар да булгалады.

Утар Аты егете Риназ белән ахирәт дуслар була алмабыз, әлбәттә, чөнки башы яшь, әмма тагын очрашырга туры килсә, күптәнге дуслар кебек рәхәтләнеп сөйләшеп торырбыз кебек. Теләсә кем белән якынаеп булмый. Кемнең кем икәнен күңел үзе сайлый һәм ялгышмый.

Балык Бистәсендә яшәүче бертуган сеңлем Розага әлеге очрашу турында әйткән идем, ул миңа бер гыйбрәт сөйләде. Аның очраклы гына танышкан бер хатыны бар икән. Сеңлем аның турыда әллә ни белми, әлеге хатын да аны якыннан белми икән. Әмма, урамда күрсә, әллә каян: «Ооо, минем матурым килә», – дип әйтә икән дә килеп күреша икән. «Мин аңа кем инде?!» – ди сеңлем. Иң кызыгы: бу хатын, өенең бусагасын атлап чыкканда, һәрвакыт: «Ходаем, миңа яхшы кешеләр белән очрашырга насыйп ит!» – дип әйтә ди. Аллаһы Тәгаләгә кайсыбыз шулай ялвара?

Очрашу, аралашу – минем өчен сулар һава кебек, шунсыз яши алмам, мөгаен. Әле бит якты дөнья йөзләрендә үз кабыкларына бикләнеп ятучылар да бар. Алар йомыкый булып тумаган, кешеләрдән, бәлки, аерым бер кешедән күңелләре кайтып, гайрәтләре чигеп, үз эчләренә бикләнгәндер.

Тормышта миңа да гел «укалы фәрештә»ләр генә очрап тормады, әмма йомыкыйга әйләнмәдем, җеннәребез килешмәгәннәрне үземнән читкә этеп куярга, андыйлар белән аралашмаска тырыштым һәм тырышам. Дөньяда яхшы кешеләр күбрәк. Шуңа шатланып яшим.

Галимнәр, очрашулар, аралашулар кешенең сәламәтлегенә уңай йогынты ясый, гомерне озайта, ди. Кайда укыганымны онытсам инде, галимнәр яман чирдән интегүчеләр белән мондый тәҗрибә үткәргән. Бер авыруны аерым палатага, икенчесен күп кешеле палатага урнаштырганнар да һәр ике очракта яман чирнең үзен ничек тотуын тикшергәннәр. Нәтиҗә кеше ышанмаслык булган. Аерым палатада ятучының савыгу мөмкинлеген – 2 процент, күп кешеле палатада ятканының 70 процент дип бәяләгәннәр. Бу минем сүз түгел, белгечләр сүзе. Кайчак тормышны да шул палаталар белән чагыштыргалыйм һәм «бергә булулары бик күңелле, әмма аерылышу бик яман» дип, «Сарман» көен сузып җибәрәм. Очрашып яшик, бер күрешү – үзе бер гомер бит ул.

Ә күрше авыл егете Риназ белән тиз генә очраша алмасак та, Утар Атыга кайткач, ул авылдашларына мине күрүе турында сөйләр. Танышларым, дусларым минем исән-сау булуыма шатланыр. Мин дә алар өчен куанып яшәрмен. Тормыш шулай бара, хәер, шулай барырга тиеш тә инде ул.

БӨТЕНДӨНЬЯ ИНФЛЯЦИЯСЕ ДУЛКЫНЫНДА,

ЯКИ ФӘКЫЙРЬЛЕКТӘН КОТЫЛЫП БУЛАМЫ?

Сүзне Росстатның яңа гына килеп ирешкән рәсми мәгълүматыннан башлыйк әле. «Май аенда, – ди илнең матди тормышын санга әйләндереп санап баручы контора, – россиялеләрнең реаль хезмәт хаклары 6,1 процентка кимегән». Мәгълүматны дөрес аңлау өчен реаль хезмәт хакы, номиналь хезмәт хакы дигән төшенчәләрне искә төшереп үтик, чөнки шул ук Росстат безгә даими рәвештә илдә уртача хезмәт хакының шактый ук зур темплар белән үсеп баруын да хәбәр итә. Әйе, әйе, кәгазьдәге хезмәт хакларын карасаң, алар, чынлап та, үсәргә мөмкин. Әмма банк картасына хезмәт хакы дигән санның зуррак булып керүе безнең хәлне бик әллә ни җиңеләйтми. Киресенчә, без айдан-айга үзебезнең фәкыйрьләнүебезне ныграк тоябыз. Март аеннан соң газета хәбәрчесе, мәсәлән, картадан бер генә тапкыр акча алды, калган барлык айлык хезмәт хаклары, кибеттән вак-төяк алганда, карта белән түләүләргә китеп бетә. Аңлашыла инде: хезмәт хакын бәяләр күтәрелүе дигән нәрсә ашап бетерә. Керемең номиналь саннарда арткан булса да, син элеккегә караганда азрак товар сатып аласың. Кесәңдәге акчага сатып алына торган товарлар һәм хезмәтләр күләме синең реаль хезмәт хакыңны күрсәтә. Реаль хезмәт хакы Росстат әйткәнгә караганда да ныграк кими ул. Беләбез бит инде: рәсми рәвештә санаганда инфляцияне кечерәк, уртача хезмәт хакларын зуррак итеп күрсәтергә тырышалар. Аннан соң хезмәт хаклары кемнәрнекедер арта, кемнәрнекедер кими дә. Хастаханәдә уртача температураның нормаль булуы хасталар юк дигән сүз түгел бит инде. Кемдер үлеп бара һәм аның тәне суына, кемнеңдер температурасы югары дигәнне генә аңлата.

Бизнес үзенә эшләүчеләргә арттырып һәм мул түләргә бик ашыкмый әле. Киресенчә, чыгымнарны киметә. «Ведомости» газетасы компанияләрнең 51 проценты персоналга чыгымнарны киметүен яза. Хезмәт хакларына бик кагылмыйлар хәзергә. Корпоратив чаралар үткәрүдән баш тарталар, хезмәткәрләрнең белемен күтәрүгә акча тотмыйлар, корпоратив төшке ашларны туктаталар, медицина иминиятләштерүен финансламыйлар икән. Компанияләрнең 20 проценты премияләр түләүдән туктаган. Болар барысы да матди якка китереп суга, әмма Росстат аны сын ук исәпкә алмаска да мөмкин.

Югалтуларны кешеләр төрлечә каплыйлар. Күндәм күпчелек билен кысып буарга тырыша, кемнәрдер өстәмә хезмәт хаклары эзли – тагын бер эшкә урнаша. Проблемага иҗади якын килеп, казна акчасын файдалануның төрле ысулларын табучылар да җитәрлек, ди. Тамбов өлкәсендә бер хатын 2019 елда ук дөньяга бөтенләй килмәгән ике баласын туды дип ялган белешмә юнәткән дә әлегә кадәр күпбалалы ана буларак пособиеләр алып яткан. Россия төбәкләре өчен социаль хәлне яхшыртуның бу ысулы гадәти хәл икән. Пермь өлкәсендә дә сигез хатын ялган белешмәләр алып әнигә әверелгәннәр һәм үзләренә пособие рәсмиләштергәннәр. Тәҗрибә уртаклашу дип аңлый күрмәгез моны, чөнки инде аларның барысына да мошенниклык буенча җинаять эшләре ачылган.

Гап-гади караклык белән матди проблемаларын чишәргә омтылучылар саны да арта. Автомобиль урлаулар саны быелның беренче алты аенда ике тапкыр үскән. Запчастьлар урлау 47 процентка арткан. Бүген иртән генә газета хәбәрчесе урамнан күрше авылда бер карчыкның битлек кигән егет кереп талап чыгуын ишетеп керде. Егетне таба алмаганнар. Этләр эз буенча суга кадәр генә барганнар... Казанда: «Эшсез калсаң, нишләргә уйлыйсың?» – дигән сорауга: «Авылга халыкны таларга кайтам», – дип җавап биргән таза егетләр бар икән.

Җинаятьчелек статистикасында күңелле хәбәрләр дә күренә. Ялган акча ясаучылар илдән китә, имеш. Һәрхәлдә, Россия Банкы быел үткән елның шул чоры белән чагыштырганда ялган акчаларның 26,96 процентка кимрәк табылуын әйтә. Акча басу рентабельлеген югалткан дип аңлыйбыз инде моны. Илдән тагын миллионерлар китә. Мәскәү тирәсендә элиталы йортларны сатуга кую кискен арткан. Китеп кая барасың, тормыш дәрәҗәсе бөтен планета буйлап түбәнәя. Төркиядә рәсми инфляция – 78,6 процент (оппозиция бер-

Илдар Мөхәммәтҗанов

ничә тапкыр зуррак булган санны атый), Аргентинада – 64, Польшада – 15,5, Англиядә – 9,4, АКШта – 9,1. Россиянең рәсми инфляциясе полякларныкыннан бик азга гына артык. Кытайда күчемсез милек сату 30 процентка кимегән, бу – 2008 ел кризисына караганда күпкә артык сан. Әле бит зур кризис шытып кына килә. Хәл торган саен кискенләшәчәк.

Мошенниклыкның да масштаблы глобаль төрләре чәчәк ата. Безгә еш кына: «Акчагызны биткойннарда саклагыз, откан булыр идегез», – диләр бит әле. Янәсе, биткойн 5 доллар вакытта алып калган булсагыз, хәзер миллионер булыр идегез. Криптоакча тирәсендә мошенниклык очраклары баштан ашкан. Соңгы сигез елда криптобиржаларның 42 проценты бер сәбәпсез юкка чыккан. Алар белән бергә клиентларның акчалары да парга әйләнгән, әлбәттә. Сәбәп белән ябылган криптобиржалар да байтак. Әйтик, криптобиржаларның 5 процентын «ватканнар», ягъни хакерлар талаган. Скам, ягъни мошенниклык нәтиҗәсендә биржаларның 9 проценты парга әйләнгән. Криптовалюта сатып алганда, син аны кемнән алуыңны белә алмыйсың бит. Криптовалюталар – иң ышанычлы һәм урланмый торган акчалар алар дигән сүз миф кына ул.

Гомумән, планета күләмендәге ашкын инфляция ул – халыкларның бөлеп барулары глобаль финанс хакимиятләренең мошенниклыгы нәтиҗәсе. Үзләре уйлап чыгарган кагыйдәләргә һәм парламентлар олигархлар файдасына кабул иткән кануннарга нигезләнеп эш иткәнгә күрә генә алар җәзаланмый. Вакытлыча җәзаланмый дип әйтик инде. Бөек кризис себеркесе миллиардерларны да бик тиз себереп түгә. Золым кылучылар Аллаһ тарафыннан җәзаланмый калмый.

Бәяләр күтәрелешенең һәм адәм балаларының фәкыйрьлеккә төшүенең сәбәбен бөек мөселман галиме ибн Тәймия болай аңлата: «Бәяләрнең күтәрелүенең бер сәбәбе кешеләрнең бер-берсен җәберләүләре булырга мөмкин», – ди. Һәм кризис котырганда фәкыйрьлектән котылуның юлын да күрсәтә: бәяләрне түбәнгә куу өчен үзара ярдәмләшүгә күчәргә чакыра. Бу хакта Аллаһның илчесе (саллаһу вә галәйһиссәләм) әйткән хәдис тә бар: «Аллаһ үзенең колына ул үзенең дин кардәшенә булышканда булыша». Мошенниклык юлы, кешеләрне талау, җәберләү, алдау аша матди муллыкка ирешеп булмый, чөнки бүгенге фәкыйрьлек ул – рухи фәкыйрьлек нәтиҗәсе. Бәяләр күтәрелүдән зарланган кардәшенә бер акыл иясе, ачуланып, болай ди: «Бәяләр күтәрелүдә синең ни эшең бар? Бәяләр түбән чагында ризыкландырган Аллаһ сине бәяләр күтәрелгәндә дә ризыкландырачак». Әлбәттә, шулай ул: шөкер итеп зарланудан баш тартучылар һәм иманында нык торучылар ач калмый беркайчан да, берникадәр сынаудан соң Аллаһның ярдәме килеп ирешә. Шуңа күрә хәтергә уеп салыйк әйдә: глобаль кризиска каршы бер генә ышанычлы корал бар. Ул – тәкъвалык.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Илдар Мөхәммәтҗанов

СОЦИАЛЬ КОНТРАКТ: КЕМГӘ ҺӘМ НИЧЕК?

Белми калмагыз!

Билгеле булганча, Татарстанда социаль контракт нигезендә дәүләт ярдәме бирелә. Әлеге ярдәм Министрлар Кабинеты карары нигезендә күрсәтелә. Без аның асылын һәм аны бирү шартларын аңлатабыз. Сорауларга республиканың Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белгечләре җавап бирде.

:: Нәрсә ул социаль контракт?

Социаль контракт – социаль яклау органы һәм катлаулы тормыш хәлендә булган кеше яки гаилә арасында дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында төзелгән килешү. Мондый ярдәм акча бирүне генә күздә тотмый, ә авырлыкны җиңеп чыгу һәм керемне арттыру өчен эш планын да тәкъдим итә.

:: Кемнәргә бирелә?

Социаль килешү нигезендәге дәүләт ярдәме аз керемле гаиләләргә (ялгыз яшәүче аз керемле гражданнарга), кереме Татарстанда билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән (2022 елда ул – 11724 сум. – **Авт.**) түбәнрәк булган гаиләләргә һәм гаиләнең милек белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе түбән булган гаиләләргә пособиеләр рәвешендә бирелә. 2022 елда программа тәкъдим итә торган юнәлешләр киңәйтелде. Ул пандемия вакытында, илдәге вазгыять шартларында эшсез калган, эш таба алмаган гражданнар өчен ярдәм буларак тәкъдим ителде. Шулай итеп, социаль контракт эш табарга, үз эшеңне ачарга (эшмәкәрлек эшчәнлеген алып барырга яки үзмәшгульлекне булдырырга), шәхси хуҗалыгыңны үстерергә һәм авыр тормыш хәленнән чыгарга (янгын, гадәттән тыш һәм башка бәла-казалар) ярдәм итәчәк.

:: Социаль контракт төзер өчен нинди шартлар үтәлергә тиеш?

Эшкә урнашу буенча социаль килешү төзү өчен, рәсми рәвештә бер ставкага, айлык хезмәт хакы минималь күләмнән ким булмаган эшкә урнашырга планлаштыручы, әмма гариза язганчы бер җирдә дә эшләмәүчеләр килә ала. Моның өчен иң элек социаль яклау бүлегендә социаль ярақлашу программасы төзелә. Аның нигезендә хезмәт һәм мәшгульлек үзәгенә эш эзләүче буларак исәпкә баскач, социаль контракт төзү датасыннан – бер ай һәм эшкә урнашу датасыннан өч ай дәвамында 11724 сум күләмендә пособие түләнә. Шунысын да билгеләп узарга кирәк: социаль контракт эшсезлек буенча пособиегә өстәмә булып тора. Ягъни килешү төзелгән очракта, эшсезлек буенча пособие туктатылмый.

:: Эшмәкәр яки үзмәшгуль буларак үз эшен ачарга теләүчеләр нәрсәне белеп торырга тиеш?

Беркайда да эшләмәүче яки керемнәре аз булган, әмма үз эшен ачарга теләүчеләр шәхси эшмәрлек яки үзмәшгульлек юнәлеше буенча гариза яза ала. Монда төп шарт булып шәхси эшмәкәр яки үзмәшгуль булып теркәлү тора. Шуңа күрә бары тик шуннан соң гына социаль яклау бүлегенә яки күпфункцияле үзәккә документлар тапшырырга кирәк булачак. Шәхси эшмәкәр яки үзмәшгуль булып эш башлап җибәрер өчен бер тапкыр 250 мең сум акча бирелә. Ярдәмне алганнан соң, сатып алынган җиһазлар өчен чек тапшырасы булачак. Аннан соң да ай саен эшмәкәрлек эшчәнлеге буенча керемнәр хакында белешмә тәкъдим итү сорала.

Шулай ук шәхси ярдәмче хуҗалык булдырырга теләгәннәр дә әлеге ярдәмгә өмет итә ала. Терлекләр (ләкин монда сыердан тыш), кош-корт алу, теплица эшчәнлеген җәелдерү өчен хөкүмәттән 75 мең сум күләмендә акча бирелә. Бу ярдәмне алыр өчен үзмәшгуль буларак теркәлергә кирәк.

:: Килешү төзү өчен кая мөрәҗәгать итәргә кирәк?

Социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме алу өчен паспорт, эшләүче гражданнарга соңгы өч айга керемнәр турында белешмә, эшләмәүче кешеләргә хезмәт кенәгәсе белән яшәү урыны буенча социаль яклау яки күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Дәүләт ярдәме билгеләнгән очракта, социаль контрактка социаль яраклашу программасы да тәкъдим ителә. Аны граждан шулай ук тормышка ашырырга тиеш булачак. Анда төрле чаралар һәм аларны башкарып чыгу вакытлары күрсәтелә: эшкә яраклы гаилә әгъзаларының эш эзләве, профессиональ белем һәм өстәмә профессиональ белем алу һәм гариза тапшыручының авыр тормыш шартларын җиңеләйтә торган башка төрле чаралар каралган була.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Сәяси сәгать

ТАРИХЧЫ ИЛНАР ГАРИФУЛЛИН:

«Рәхәт вакытта үзгәрешләр булмый»

Без әле кая барабыз? Дөньяда ниләр бар? Бу сорауларга җавапны тарихчы Илнар ГАРИФУЛЛИН белән эзлибез.

:: Океан артындагы Ак йортның элеккеге хуҗасы Дональд Трамп фикеренчә, АКШка СССР язмышын кабатлау куркынычы яный. Сәяси уен вакытында әйтелгән фикер генәме бу, әллә аларда чыннан да хәлләр мөшкелме? Ерак булса да, безгә дә кагылачак бит.

– Бу сүзләрне АКШның бүгенге башлыгы Байденга каршы әйтелгән дип кабул итәргә кирәктер. Аларда бит сайлау системасы безнекеннән үзгәрәк. Парламентны, әйтик, өч өлешкә бүлеп сайлыйлар. Тавыш бирү вакыты якынлашкан саен популист сүзләр күбәя. АКШның икътисадына килгәндә, бу илнең элгәрәк тә мондый авыр вакытларны кичергәне булды. Әйтик, Вьетнам сугышыннан соң анда зур социаль проблемалар калкып чыкканы билгеле. Әмма йөзеп чыга алганнар. Бу юлы да шулай булыр дип фаразлыйм. Ник дигәндә, аларның сәяси системасы бик йомшак, үзгәреп тора. Авыр булса да, вазгыятьне үзләре өчен уңай якка бора алырлар. Җитмәсә, дөнья күләмендә долларның көче әле дә җитәрлек. Аны актив кулланалар. Бурычлары күп дип әйтәләр. Тик АКШның икътисады җимерелә икән, үз артыннан бөтен дөньяны тартачак. Элеккеге кебек үк булмаса да, безнең дә аңа бәйләнешебез бар. Кытай турында әйткән дә юк. Шуңа күрә бу илгә начар киләчәк теләүчеләр күп дип әйтмәс идем.

:: Узган атнада Россия Президенты Владимир Путин Иранга барды. Киләсе атнада Төркия Президенты Эрдоганны Сочида көтәләр. Истанбулда «Фәнәрбахчә» белән Киев «Динамо»сы арасындагы футбол очрашуында җирле җанатарлар «Владимир Путин» дип кычкырып утыра. Россиянең иң якын дуслары Төркия белән Иранмы?

– Аларны дуслар түгел, бүгенге шартлардагы вакытлыча союзниклар дип атар идем. Иран да санкцияләр астында яши. Төркиягә дә көчле басым ясала. Җитмәсә, Төркия Шәрык илләрендә, Урта Азиядә үз йогынтысын киңәйтергә тырыша. Уртак мәнфәгатьләребез бар. Бүгенге вазгыять үзгәрсә, мондый ук якынаю, берләшү булмас иде, бәлки. Иран белән чагыштырганда, Төркия белән бәйләнешләр якынрак. Бу мөнәсәбәтләрдә Татарстанның да роле бар. Миңа калса, төрекләрдә Россия үрнәк алырлык сыйфат бар. Алар кайда, нинди вазгыять булса да, үз мәнфәгатьләреннән файдалана белә, беренче чиратта үзләренә уңайлы якны эзли. Татар милләтенә дә җитми мондый сыйфат.

:: Ә Кытай кайда?

– Санкция шартларында ярдәм була дисәләр дә, бу бик сизелми. Кытай белән чагыштырганда, Иран белән Төркия үз сүзләрен күбрәк тормышка ашыра.

:: Соңгы вакытта матбугатта махсус операциягә карата мөнәсәбәт үзгәрү сизелә. Игътибар кимеде, тынычлану барлыкка килде кебек. Әллә бу вазгыятькә ияләшүме?

– Әлбәттә, ияләшү. Кеше авыр вазгыятькә дә, бәхетле тормышка да ияләшә. Җәйге вакыт икән ул онытмыйк. Кеше авылга, бакчасына, ялга китә. Бездә хояшлы, җылы вакыт болай да аз. Андый вакытта тормыштагы мәшәкатьләрдән онытылырга, игътибар итмәскә тырышабыз. Мәгълүмат чаралары да шул юлдан бара. Икенчедән, гади халык махсус операциянең ни белән тәмамланасын белми. Шуңа күрә халыкның да кызыксынуы кими.

:: Бу көннәрдә Казанда Бөтендөнья татар конгрессының VIII съезды узачак. Әлеге җыеннан нәрсә көтәргә? Бүгенге шартларда милли мәсьәләләргә зур игътибар биреп буламы?

– Барысы да конгресс җитәкчелегеннән тора. Әйтик, Милли Шурага кемнәр тәкъдим ителер? Миңа калса, составның ким дигәндә 50 процентын үзгәртергә кирәк. Чөнки вазгыять тә үзгәрә. Икенчедән, анда яшьләр юк. Ә аларсыз алга китеш булмаячак.

Икътисадта авырлыклар һәрвакыт була. Миңа калса, андый вакытта, киресенчә, чыгу юлларын эзләргә кирәк. Рәхәт вакытта бернинди үзгәреш булмый. Тарих та шуны раслый: алар авыр вакыттан соң башлана. Милләт саклансын, кирәкле юллар табылсын өчен үзгәрешләр кирәк. Исегезгә төшерәм: 2007, 2012 елларда да мондый җыеннар узды. Ул вакытта илдә барысы да тыныч, вазгыять тә яхшы иде. Без дә, Татарстан үсә, дип шатландык, киләчәк турында артык уйламадык. Милләт язмышы турында 2016–2017 елларда ныклап уйлана башладык. Шуңа күрә хәлләр авыр дип кул селтәү дөрес түгел, киресенчә, эшләргә, үз мәнфәгатьләребезне кайгыртырга кирәк.

Әңгәмәдәш – Илнар ХӨСНУЛЛИН

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Илдар Мөхәммәтҗанов

АГУЛЫ БАЛ

Рапс белән бәла чәчәк ата

«Татарстан умартачылары» иҗтимагый оешмасы советы рәисе Шәүкәт Хәйруллин сүзләренчә, быел харап булган бал корты гаиләләре саны, узган биш ел белән чагыштырганда, иң күбе. Чынлыкта күпме бал корты гаиләсе харап булуын исәпләп чыгару җиңел эш түгел. Шуңа күрә ул саннарны якынча әйтте.

– 2019–2020 елларда 5 меңләп тирәсе бал корты гаиләсе үлде. Узган ел вазгыять сизелерлек яхшырды. 2500 тирәсе бал корты гаиләсе һәлак булды. Быел да яхшыга өметләнгән идек, ләкин, кызганыч, киресенчә килеп чыкты. Инде бүгенгә харап булган корт гаиләләре 5 мең тирәсенә җитте, – диде ул.

Бу атнада гына Биектау, Азнакай, Лениногорск районнарыннан күңелсез хәбәрләр килеп ирешә. Мәсәлән, Биектау районының Ташлы Кавал авылында Хәбибуллиннар хуҗалыгында – 278, Лениногорск районында 500ләп корт гаиләсе һәлак булган. Алдан фаразлау буенча, моның сәбәбе – рапс басуларын химикатлар белән эшкәртү.

– Умартачылык белән яшәгән кешеләр өчен бал кортларын югалту – зур фаҗига, чөнки алар төп табышыннан колак кага дигән сүз, – ди Шәүкәт Хәйруллин. – Кемдер тәзелеш башлап җибәргән, кемдер кредит алган, кемнеңдер баласын мәктәпкә әзерлисе бар. Алар барысы да – гап-гади кешеләр, араларында байлар юк. Бу акча югалту гына түгел, ә якын дустыңны, ышанычыңны югалту белән бер. Чөнки без елның 360 көнен шуның белән яшибез. Үстерәсең, карыйсың да бер матур көнне барысы да юкка чыксын әле!

Шәүкәт Хәйруллин әйтүенчә, күңелсез хәлләр ел да бер үк районнарда (Арча, Питрәч, Саба, Әлмәт районнары) кабатлана.

– Димәк, башка районнарда моны хәл итү юлларын тапканнар. Тәҗрибә уртаклашырга, сөйләшергә, аңлашырга, берләшергә кирәк. Кайбер агрофирмалар умарталарны күчереп торырга машиналарга кадәр тәкъдим итә, уртага салып сөйләшәләр, кызыксыналар. Менә шулай эшләгәндә генә нәтиҗә турында сөйләшергә мөмкин, – ди ул.

Шул ук вакытта, Шәүкәт Хәйруллин фикеренчә, умартачыларның үзләренең дә гаебе бар. «Активлык җитеп бетми. Әгәр халык үзе уяу булып, тиз арада күтәрелеп чыкса, мондый хәлләр кабатланмас иде. Халык кайда битараф, шунда агулыйлар», – дип нәтиҗә ясый ул.

Зыян күрүчеләр арасында Питрәч районының Иске Кощаково авылыннан Равил Нигъмәтуллин да бар. Аның кызы Сәрия Акташ сөйләвенчә, бал кортлары узган якшәмбедә үлә башлаган.

– Ул көнне әтием безгә килде дә: «Бар да бетте, быел бал булмый. Кортлар тезелешеп ята», – диде. 32 гаиләнең 16сы гына исән. Эшләүче кортларның күпчелеге харап булды. Көчтән килгән яшь кортлар гына калды. Белмим, бал булырмы, булса да, аны ашарга һәм сатарга ярармы? Минем дүрт балам бар. Аларга да бирергә шикләнәчәкмен. Комиссия килеп, пробалар алып китте. Башта без аны үзебездә генә булгандыр дип уйладык, тик күрше-тирә авылларда да шундый очраклар булуы ачыкланды, – диде.

Ләкин, хуҗабикә сүзләренчә, матди зыяннан бигрәк, рухи зыян күбрәк.

– Әтием умартачылык белән инфарктан соң шөгыльләнә башлады. Аның өчен юаныч, шөгыль иде ул. Бик нык кәефе төште. Башка шөгыльләнмим, ди. Судка бирүдән дә мәгънә юк. Дәлилләү бик мәшәкатьле, чыгымы да күп, – ди Сәрия ханым.

Азнакай районының Әсәй авылында яшәүче Расыйх Шакиров сүзләре буенча, мондый проблема Азнакай районында да бар. Быел берничә авылдагы хуҗалыклар зыян күргән. Дөрес, үлгән умарта ояларының төгәл санын әйтеп бирә алмады.

– Рапс авыллардан 5 чакрым ераклыкта чәчелергә тиеш, ләкин бу таләпләрнең берсе дә үтәлми. Ике арага саклагыч полоса буларак карабодай чәчсеннәр иде, – ди ул. – Бал кортлары агулану белән үк үлмәскә дә мөмкин. Алар тора-бара харап була. Монда барысы да – район башлыгыннан башлап тикшерү органнары, умартачылар бергә эшләргә тиеш.

Хәл итәргә мөмкин

Умартачыларның теләкләре аңлашыла да: эшкәртсеннәр, тик билгеле бер таләпләрне генә үтәсеннәр. Аерым алганда, умартачылар энтомофиль культураларны эшкәрткән вакытта куркынычлылыгы 1 һәм 2 нче класс булган инсектицидлар белән эшкәртүне тыярга таләп итә. Кырларны эшкәрткән вакытта бал кортларының игътибарын җәлеп итәр өчен махсус азык базасы булдыру да бөҗәкләрне саклап калыр иде, ди алар. Болардан тыш, алар кортлар очкан көндезге сәгатьләрдә агулаган өчен җаваплылыкны арттыруны сорый. Өченчедән, сөйләшүләрне көздән үк башларга кирәклеген әйтә.

Бер караганда, әлеге хәлләрне булдырмый калуның тәртипләре эшләнгән дә. Әледән-әле алдан кисәтү, зарарсыз биопрепаратлардан файдалану турында әйтелә, һәр районда пестицидлар һәм агрохимикатлар кулланганда закон бозу очракларын булдырмый калу максатыннан эшче төркем һәм «Ватсап»та группалар булдырылды. Инвесторларга һәм фермерларга кисәтү хатлары таратыла. Тик Арча районының актив умартачысы Ләлә Шакирова фикеренчә, гамәлдә болар эшләми яки проблеманы хәл итми. «Кортларны тиз арада кая да булса алып китү яки ябып тору – бар кешегә дә туры килә торган чара түгел», – ди ул.

Сүз уңаеннан, Шакировлар әлеге проблеманы ишетеп кенә белми. Ике ел рәттән Шекә авылында яшәүче әтисе Нурулла Закировка авырлык килгән. Узган ел – 30лап оясы, быелның июнендә умарталарның 50 проценты зыян күргән. Үлгән кортларны анализга җибәргәч, аларда ике төрле пестицид булуы ачыкланган. Шулай да, Ләлә Шакирова сүзләренчә, проблема хәл ителмәслек түгел.

– Агрофирмалар чүп үләннәргә, корткычларга каршы көрәшү өчен арзанлы, әмма халыкка да, табигатькә дә зыянлы пестицидлар сайлый. Моны югарыдан тыярга кирәк. Ни өчен аграрийларның куркынычлылыгы өченче класс булган препаратлар белән эшлиселәре килми? Чөнки алары дүрт тапкыр кыйммәтрәк һәм нәтиҗәсе озакка бармый. Икенчедән, умартачыларның үзләренең проблемаларына, туган якларына битарафлыгы. Күпчелек кеше, төрле сәбәпләр аркасында, тел яшерү яклы. Кемдер мәшәкатеннән, кемдер чыгымыннан, кемдер кешедән курка, кемнедер дөреслеккә ышанмау туктата. Безгә берләшеп эшләү җитми. Өченчедән, рәсми органнарның безне берсеннән икенчесенә куып йөртүләре тәмам алҗытты. Бары тик безнең мәнфәгатьләрне генә яклаучы вәкаләтле ведомство булдырырга кирәк, – диде Ләлә Шакирова.

Умартачылар сүзләренчә, үлгән бал кортлары өчен компенсация алу да сират күпере кичү белән бер. Бик күп нечкәлекләре, авырлыклары бар. Шунлыктан зыян күргән өчен акча алучылар бик аз.

Сөйләшү кирәк

Бал кортлары үлү очраклары буенча Россельхознадзор хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе тикшерү башлап җибәрде. Нәтиҗәләр билгеле булгач кына тиешле чаралар күреләчәк.

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы безгә биргән җавап хатыннан аңлашылганча, бал кортлары аграрийларның энтомофиль культураларны (бөҗәкләр белән серкәләнүче культуралар) эшкәрткән вакытта куркынычлылыгы 1 нче класс булган препаратлар кулланудан харап булырга мөмкин дип фаразлана. Ләкин төгәл нәтиҗә, алда язып узганча, анализлардан соң гына ясалачак.

– Кызганыч, республикада бал кортларының күпләп үлү очраклары ешайды. Төгәл саннарны әлегә әйтү читен. Быелгы сезонда без Әлмәт, Аксубай, Лениногорск, Питрәч районнары умартачыларыннан мөрәҗәгатьләр алдык. Ләкин барысы да проблемалар турында хәбәр итми, – диде министр урынбасары Ленар Гарипов.

Аның фикеренчә, профилактика эшләре алып баруга умарта паспортлары булмау да комачаулый. Татарстанда умарталыкларның нибары 36 проценты гына паспорт алган.

– Шунлыктан умарталыкның урнашкан урынын ачыклау авыр. Паспорт ясату мәҗбүри. Бу, агуланган очракта, судта да кирәкле документ. Шулай ук суд, кисәтү алганнан соң, умартачының зыян күрмәс өчен, нинди чаралар күрүе белән дә кызыксыначак, – дип кисәтә министр урынбасары.

Татарстан Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек комитеты рәисе урынбасары Таһир Һадиев фикеренчә, бу четерекле мәсьәләдә ике як турында да уйларга кирәк.

– Бу очракта без ике сорауга җавап бирергә тиешбез: авылда эшләүче кешеләрне сакларга һәм республика халкын азык-төлек белән тәэмин итәргә телибезме? – ди ул, умартачыларның иң куркыныч саналган химикатлардан баш тарту белән бәйле үтенечен шәрехләп. – Чөнки химик ысулдан ваз кичкән очракта уңыш күләме өч тапкыр кимеячәк һәм 2 млн тоннага да җитмәячәк. Бу технологияләр бүген уңышны тотрыклы һәм күп итеп алырга мөмкинлекләр бирә. Умартачылар әйткән пестицидларны кулланмаган очракта, кайбер культураларны бөтенләй үстермәскә туры киләчәк. Арпа уңышы да бермә-бер кимеячәк. Пестицидларның барысы да теркәлү узган, рөхсәт ителгән каталогы бар. Бүген генә аларны алыштыручы препаратлар юк. Димәк, алтын урталыкны табарга кирәк.

Аның фикеренчә, эре агрохолдинглар да законда күрсәтелгән регламентларның үтәлешен тәэмин итәргә тиеш:

– Бу мәсьәлә буенча Россиядә дә, Татарстанда да закон кабул ителде, аны җиренә җиткереп үтәргә генә кирәк. Ике яклы сөйләшү мәҗбүри. Җирле үзидарәләрдә дә активлык сорала. Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Россельхознадзор да үз сүзләрен тулы һәм аңлаешлы итеп әйтергә тиеш. Кыскасы, бу тема үзенең чишелешен таләп итә. Монда җиңүчеләр дә, җиңелүчеләр дә була алмый.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Фикер

Таһир ҺАДИЕВ, Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек комитеты рәисе урынбасары:

– Умарта кортының авыл хуҗалыгында роле зур. Күпчелек культураларны бал кортлары серкәләндерә. Серкәләндерүнең 80 проценты нәкъ менә шушы бөҗәкләргә туры килә. Бер корт көненә – 4 мең, ә яхшы корт гаиләсе 40–50 млн чәчәккә куна. Аларның тырышып эшләүләре нәтиҗәсендә көнбагыш, карабодай, кориандр уңышы 20–30 процентка күтәрелә. Җиләк-җимеш агачларының уңышы исә 30–40 процентка арта. Шулай итеп, бал кортлары ике эшне бергә алып бара. Шулай булуга карамастан, бу мәсьәләдә бер якның мәнфәгатен генә канәгатьләндерергә ярамый. Бу – без уйлаганга караганда күпкә нечкәрәк тема. Шуңа күрә бик җентекле өйрәну таләп итә.

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

АШАМАСАҢ ДА ТАШЛАМА

Россиядә артык азык-төлекне бушлай таратуга корылган «фудшеринг» юнәлешен законлаштырмакчылар. Бу үз чиратында бер миллион тоннага якын ризыкны чүплеккә чыгарып ташлауны туктатырга мөмкинлек бирәчәк, утильләштерү мәшәкатен дә киметәчәк. Үзенә күрә хәйрия чарасы да. Кайбер зур сәүдә челтәрләре бушлай ризык таратуны башларга әзер икән инде. Сынала торган төбәкләр – Мәскәү, Чиләбе һәм Санкт-Петербург. Исрафлыктан бу гына коткарырмы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Чишмә башы

Язмабызны саннардан башлыйк. Ел саен 1,6 трлн сумлык 17 млн тонна азык-төлек чүплеккә һәм полигоннарга ташлана. Белгечләр сүзенә ышансаң, кулланылмаган бу продукция 2,5 млн тонна аммиак, углекислый газ һәм метан бүлеп чыгара. Шул ук вакытта Россия халкының 11 проценты яшәү минимумыннан түбәнрәк суммага көн күрә. Ташланган азык-төлек 30 млн кешене ашатырга җитәр иде.

Россия Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы шушы көннәрдә зур сәүдә челтәрләрендә фудшеринг программасын җәелдерү тәкъдимен хуплап чыгыш ясады. Ягъни кибетләр куллану вакыты чыгарга күп калмаган азык-төлекне мохтаҗларга бушлай таратачак. Сүз кешеләр турында гына бармый. Мохтаҗ дигәнне киңрәк тә карарга мөмкин. Билгеле, таратылачак ризыкның сыйфаты да, барлык белешмәләре дә тәртиптә булырга тиеш.

Фудшеринг турында күптән сөйлиләр, хәйриячелек буларак аның белән халык азмы-күпме шөгыльләнә дә. Әмма ул закон белән беркетелгән юнәлеш саналмый. Тик юлда таш булып яткан сәбәпләр бу гына түгел.

Закон кибетләрдән яраклылык вакыты чыккан продукцияне утильләштерүне таләп итә. Министрлык тәкъдименә барысы да яхшы кебек, әмма сәүдә итүчеләр өчен түгел. Фудшеринг программасы аркасында алар акча югалтачак. Утильләштерүдән дә кыйммәткәрәк төшәчәк әле ул. Хәйрия чарасы буларак азык-төлек тарату да аны салымнан азат итми. НДСны барыбер түлисе. Бу күпчелек очракта товар бәясенең 20 проценты диярлек. Шуңа күрә дә кибетләргә бушлай таратканчы чүплеккә чыгарып ташлау отышлырак. Ризыкны юк итеп, акт нигезендә компенсация дә алырга мөмкинлек бар бит.

Шулай да Салым федераль хезмәтендә законнарга карата кирәкле төзәтмәләрне быел көзгә карарга вәгъдә итәләр. Фудшерингка багышланган закон проектын исә Дәүләт Думасының көзге утырышында кабул да итәрләр дигән өмет бар.

Кайбер сәүдә челтәрләре закон үзгәрешләрен көтеп тормаска булды. «Магнит» һәм «X5 Group» ритейлеры («Карусель», «Пятерочка», «Перекресток» кибетләре керә. – **Авт.**) азык-төлек таратуны сынау рәвешендә башламакчы инде. Дөрес, Россиянең барлык шәһәрләрендә дә түгел. Әлегә Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Чиләбедә сынап караячаклар.

«Магнит» кибетенең тотрыклы үсеш буенча идарәсе җитәкчесе Надежда Галактионованың рәсми сайттагы җавабыннан аңлашылганча, сәүдә ноктасының мохтаҗларга азык-төлек өләшү буенча волонтерлык оешмалары белән эшләү тәҗрибәсе бар. Әйтик, пандемия чорында гына да илнең 24 төбәгендә яшәүче аз керемле гражданнарга 350 меңләп азык-төлек тупланмасы таратылган. «Моны фудшеринг кысасында да башкарып була. Мохтаҗларга ярдәм итүдән тыш, бу әле калдыклар күләмен киметергә мөмкинлек бирәчәк», – дигән кибет вәкиле. Димәк, кибет үзе азык-төлек тарату белән шөгыльләнмәячәк. Аны хәйрия фондларында волонтерлар таратачак.

Истә тот!

- Фудшеринг – мөмкин булганча күбрәк ризыкны чүплектән «коткару» юнәлеше. Фриганнар белән бутамаска. Сүз уңаеннан, «ВТ» әлеге ике юнәлеш турында да язма әзерләгән иде. Фриганнар – чүплектә казынып, аннан азык-төлек һәм башка кирәк-яраклар табып, шулар хисабына яшәүчеләр. Алар да исрафлыкка каршы чыга.
- Фудшеринг белән шөгыльләнү – мохтаҗ, фәкыйрь булу дигән сүз түгел. Моның берниндә дә ояты юк. Кулланырга яраклы ризыкны чүплеккә чыгарып ташламыйча, исраф итмичә, җәмгыятькә дә, экологиягә дә файда китерергә була. Мәсәлән, бер бутербродны чүп чиләгенә ташлау – канализациягә 90 л су агызуга тиң.
- Зур шәһәрләрдә фудшеринг белән шөгыльләнүчеләрнең махсус төркемнәре бар. Аларны социаль челтәрләрдә табарга мөмкин.
- Исраф кылмау, башкалар белән бүлешү – мәрхәмәтлелек үрнәге дә әле ул.

Кадере артырмы?

Фудшеринг ике куянның койрыгын бер юлы тотарга мөмкинлек бирәчәк. Казан федераль университетының табигатьне тергезү һәм су ресурсларын файдалану кафедрасы ассистенты, мөгаллим, эколог Наил Назаров шундый фикердә.

– Азык-төлекне рациональ куллану ягыннан һәм фәкыйрьлек белән көрәшү күзлегеннән, бу фикерне бик дөрес дип саныйм. Экологик яктан да, минемчә, файдалы булырга тиеш. Чөнки бу чүплекләрдә органик калдыкларны киметергә ярдәм итәчәк. Бу исә, үз чиратында, мондый калдыклар белән тукланучы синантроп биологик төрләрнең артык үрчүен чикләячәк һәм шәһәр мохитен сизелерлек дәрәҗәдә яхшыртачак. Аңлатып үтик: синантроп төрләр кешеләр күпләп яши торган урыннарда очрый. Мәсәлән, күселәр, тычканнар, чәүкәләр һәм каргалар. Чүплекләрдә тукланып, алар авыл-шәһәрләрдә бик күпләп тупланалар, саннары табигатькә кирәгеннән бик күпкә артып китә. Бу кешеләр һәм хайваннар арасында кайбер йогышлы авырулар таралуга да сәбәп була, – дип аңлатты белгеч.

Эколог әйтүенчә, куллану вакыты чыгып бара торган азык-төлеккә башкача да икенче гомер бүләк итәргә мөмкин. «Чит илләрдәге күп кенә кибетләр куллану вакыты чыгарга бер тәүлек калган ризыкларны зур ташлама белән сата яки бушка бирә. Шулай ук, вакыты чыккан ризыкларны, аларның химик составына карап, авыл хуҗалыгы тармагында кулланалар. Әйтик, хайваннар өчен биологик өстәмәләр (биодобавки) һәм комбиазыклар җитештерүдә. Бу – ризыкны икенчел эшкәртү һәм куллануның бик отышлы ысулы», – ди ул.

Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының тәкъдименә политконсультант Дарья Полянкина да үз фикерен белдерде. Аның сүзләренчә, хәйриячелек юлына басам дип, әлеге идеяләрне тормышка ашырачак төп кеше – Россиядә яшәүче исәпкә алынмый. Төгәлрәге, илдә яшәүченең менталитеты.

Сан

Фудшеринг Россиядә елына 7 мең тонна азык-төлекне чүплектән коткарырга ярдәм итә.

– Дәүләт аңа куллану вакыты менә-менә чыгам дип торган бушлай азык-төлек рәвешендә социаль ярдәм тәкъдим иткәндә, россияле үзен ничек хис итәр соң? Бу аның иҗтимагый һәм хакимият институтларына мөнәсәбәтендә нинди чагылыш табар? – дип уйлана белгеч. – Министрлыкның бу тәкъдиме күп сораулар калдыра. Иң элек – этик мәгънәдә-геләрен.

Эко-блогер Анастасия Приказчикова фудшеринг хәрәкәтен хуплаучылар рәтеннән. Аныңча, экологик проблемаларны хәл итүгә һәм артык куллануны киметүгә һәр кеше үз өлешен кертә ала. Кайбер кагыйдәләрне дә үтәргә кирәк.

– Иң гади киңәш – ашый алган кадәр генә сатып алырга, ашарга, мөмкин кадәр азрак ризыкны ташларга кирәк. Монысы өчен көндәлектә кулланырлык кагыйдәләр дә бар. Әйтик, калдык азык-төлекне үтәкүренмәле, ә иң яхшысы – пыяла савыт-сабада, контейнерларда саклагыз. Савыт төбендә күпме ризык калганын күреп торгач, аның турында онытту ихтималы да кими. Димәк, йә ашап бетерәчәксез, йә башкача кулланачаксыз. Моңа мөмкинлек биргән азык-төлекне туңдыргычта саклагыз. Хәзер махсус пакетлар да бар, шуларга салып, катырырга куярга мөмкин. Бүген һәм тиз арада ашап бетерергә кирәк ризыклар өчен суыткычта махсус урын билгеләп куегыз. Мин, мәсәлән, өске катны шуның өчен тотам. Яңа ризык әзерләр алдыннан шул катка игътибар итегез. Бәлки, әле ашарга яраклы берәр нәрсә калгандыр, – дип уртаклашты ул.

1 август | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК» 12+
10.00, 00.50 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА» 16+
11.00 «Татар халык җырлары» 0+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 00.00 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Заповедники РФ» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 Бөтендөнья татар конгрессының VIII съезды ачылышы 0+
01.20 «Вызов 112» 16+
01.30 «Рыцари вечности». Каюм Насыри 12+
01.45 «Фолиант в столетнем переплёте». К 1100-летию принятия ислама Волжский Булгарией 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Фатыйх Хөсни турында телеочерк 6+
15.30 «Ватандашлар» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 23.25, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
19.35 «Татарлар» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Бөтендөнья татар конгрессының VIII съезды ачылышы» 6+
00.40 «Татарлар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
04.15 «Башваткыч» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Карина Андоленко, Антон Хабаров, Александр Бухаров. «ОТЧИМ» (S) 16+
23.45 «Большая игра» 16+
00.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.0, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
23.55 Мария Андреева, Евгений Цыганов, Надежда Маркина, Пётр Зайченко, Борис Невзоров. «СОФИЯ» 16+
01.05 Екатерина Кузнецова, Владимир Жеребцов, Леонид Громов, Александр Самойленко, Екатерина Васильева, Борис Галкин. «КОРОЛЕВА БАНДИТОВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.35, 14.55, 18.00 Новости
06.05, 23.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.40 Специальный репортаж 12+
09.20 «КРЮК» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.00 «ПОБЕГ» 16+
15.55 Смешанные единоборства. INVICTA FC. Таниша Теннант против Ольги Рубин. Трансляция из США 16+
16.45 Международные соревнования «Игры дружбы-2022». Синхронное плавание. Прямая трансляция из Казани
18.05 «Громко». Прямой эфир
19.05 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
19.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Рубин» (Казань) – «Уфа». Прямая трансляция
22.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.15 Тотальный футбол 12+
00.45 «ВИРУСНЫЙ ФАКТОР» 16+
03.15 Новости 0+

НТВ

05.00 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.50 Павел Майков, Виталий Кудрявцев, Александр Большаков, Александр Барановский. «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
21.40 Премьера. Остросюжетный сериал «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Преступления страсти» 16+
07.00 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.25 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.30 «Порча». «Покойник» 16+
14.00 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «Преступления страсти» 16+
19.00 «МОЯ ЧУЖАЯ ДОЧКА» 16+
22.45 «Порча» 16+
23.20 «Знахарка» 16+
23.50 «Верну любимого» 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.10 «Тест на отцовство» 16+
02.50 «Давай разведёмся!» 16+
05.20 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

06.50 «КАДЕТЫ» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.30, 01.10 «ПЯТЕРО С НЕБА» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
13.35, 14.05 «Легенды армии». Валерий Востротин 12+
14.00 Военные новости 16+
14.30 «БАТЯ» 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Битва оружейников». Док. сериал. «Пулеметы» 16+
19.40 «Загадки века». Док. сериал. «Почему Сталин пощадил Гитлера» 12+
22.55 «СЛУШАТЬ В ОТСЕКАХ» 12+
02.40 «МООНЗУНД» 12+
05.00 «Раздвигая льды». Док. фильм 12+

2 август | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК» 12+
10.00, 00.50 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 14.30 «Татарлар» 12+
12.00, 00.00 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тәймә» 0+
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 Бөтендөнья татар конгрессы VIII съездының пленар утырышы 0+
01.30 «Видеоспорт» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Рафкать Бикчәнтәев турында телеочерк 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Бөтендөнья татар конгрессы VIII съездының пленар утырышы» 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
19.35 «Татарлар» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
00.40 «Татарлар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «ОТЧИМ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.45 «Большая игра» 16+
00.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 Мария Андреева, Евгений Цыганов, Надежда Маркина, Пётр Зайченко, Борис Невзоров. «СОФИЯ» 16+
01.05 Екатерина Кузнецова, Владимир Жеребцов, Леонид Громов, Александр Самойленко, Екатерина Васильева, Борис Галкин. «КОРОЛЕВА БАНДИТОВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.30, 14.45, 17.50, 21.15 Новости
06.05, 17.00, 22.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.35, 00.50 Специальный репортаж 12+
09.20 «КРЮК» 16+
11.00 Матч! Парад 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55, 14.50 «ПОБЕГ» 16+
15.45 Международные соревнования «Игры дружбы-2022». Синхронное плавание. Прямая трансляция из Казани
17.55 Лёгкая атлетика. Чемпионат России. Прямая трансляция из Чебоксар
21.20 Смешанные единоборства. Open FC. Руслан Проводников против Али Багаутинова. Трансляция из Москвы 16+
23.00 «СЛЕД ПИРАНЬИ» 16+
01.10 Футбол. Южноамериканский Кубок. 1/4 финала. «Насьональ» (Уругвай) – «Атлетико Гоияниенсе» (Бразилия). Прямая трансляция

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.50 Остросюжетный сериал «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
21.40 Премьера. Остросюжетный сериал «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ» (S) 16+
00.00 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.25 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.30 «Порча». «Залетайка» 16+
14.00 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «Преступления страсти» 16+
19.00 «МЕНЯ ЗОВУТ САША» 16+
22.45 «Порча» 16+
23.20 «Знахарка» 16+
23.50 «Верну любимого» 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.10 «Тест на отцовство» 16+
02.50 «Давай разведёмся!» 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «БАТЯ» 16+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
09.35, 00.15 «ГОЛУБЫЕ МОЛНИИ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «Легенды армии». Василий Маргелов 12+
14.30 «БАТЯ» 16+
18.50 «2 августа – День воздушно-десантных войск». Док. фильм 16+
19.40 «Улика из прошлого». «Франция против Гитлера. Последняя тайна эскадрильи «Нормандия-Неман» 16+
22.55 «ЧЕРНЫЙ ОКЕАН» 16+
01.40 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА» 12+
03.10 «ПИРОЖКИ С КАРТОШКОЙ» 16+

Рәсми документлар

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БОЕРЫГЫ

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен формалаштыру турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокуклары төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен формалаштыру турында Татарстан Республикасы Президентының кушымтада бирелә торган белдерүе текстын расларга һәм аны «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында бастырып чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсенә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе составына билгеләп кую өчен хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалар кандидатуралары турында тәкъдимнәрне гомумиләштерергә, аларны 2022 елның 12 сентябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентына тәкъдим итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесенә йөкләргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
Р.Н. Миңнеханов

Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 26 июлендәге 238 номерлы боерыгына кушымта

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен формалаштыру турында Татарстан Республикасы Президенты белдерүе

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең вәкаләтләр срогы тәмамлану белән бәйле рәвештә һәм «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокуклары төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең яңа составын формалаштыру башлана.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе составына билгеләп кую өчен хәлиткеч тавыш хокукына ия кандидатуралар турындагы тәкъдимнәр һәм аларга теркәп бирелүче, закон таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән документлар әлеге белдерү рәсми басылып чыккан көннән 30 көн дәвамында кабул ителә.

Әлеге тәкъдимнәр түбәндәге адреска почта аша юллана: 420014, Казан шәһәре, Кремль, 5 нче корпус, Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе (Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе) яисә эш көннәрендә 9 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кулдан тапшырыла (207 нче кабинет).

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен формалаштыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 147 статьясындагы 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен формалаштыру турындагы хәбәрнамәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе составына билгеләп кую өчен хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалар кандидатуралары хакындагы тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм 2022 елның 12 сентябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына бәяләмә тапшырырга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен формалаштыру турындагы хәбәрнамәне 2022 елның 30 июленнән дә соңга калмыйча «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 7 июле № 1511-VI ДС

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2022 елның 7 июлендәге 1511-VI ДС номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен формалаштыру турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы

ХӘБӘРНАМӘСЕ

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең вәкаләтләр чоры тәмамлануга бәйле рәвештә һәм «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең яңа составы формалаша башлый.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе составына билгеләп кую өчен кандидатуралар турында тәкъдимнәр (Россия Федерациясе гражданының күрсәтелгән комиссия составына керүгә язмача килешүе белән) әлеге хәбәр рәсми басылып чыккан көннән 30 көн дәвамында кабул ителә. Күрсәтелгән тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына эш көннәрендә 9 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрелә: 420060, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1 нче йорт.

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

ЧЕРЕМ ИТҮ ГЕНӘ, ДИМӘ

Көндез черем итеп алу – күпләрнең яраткан гадәте, кайберәүләрнең күптәнге хыялы. Ничек кенә булмасын, организмның көн уртасында ял соравы – гадәти хәл. Белгечләр исә, көндезге йокы файдалы булудан бигрәк, чир билгесе дә булырга мөмкин, дип кисәтә.

Көндез черем итеп алуның бар хикмәте турында табиб-невролог, сомнолог Кадрия ВӘЛИЕВА сөйләде.

➤Көндез йоклау, черем итеп алуга элек-электән үзгә караш яши. Ышерен-батырын түгел, ул үзенә күрә бер ялкаулык билгесе буларак та кабул ителә. Әмма көндезге йокының файдалы яклары да җитәрлек. Чама хисен генә онытмаска кирәк!

➤Көндез черем итеп алуны төнге йокыга өстәмә дисәк, дөресрәк булыр. Әгәр икесен бергә кушкач, кешегә бер тәүлеккә җитәрлек йокы сәгатьләре җыелса, көндез черем итеп алу – аңа файдага гына дигән сүз. Көндезге һәм төнге йокы сәгатьләре тиешле нормадан артып китсә, көндез йоклауның организм өчен бернинди шифасы да юк.

➤Ашаганда гына түгел, йоклаганда да чама хисен югалтырга ярамый. Көндез артык озак йоклау аркасында, кеше төнлә йокысызлыктан интегергә мөмкин. Күпсанлы тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, көннең икенче яртысында акыл хезмәтенә күче сүрелгән кеше, гадәттә, көндез 40 минуттан да озаграк йоклый. Көндез артык озак йоклаган кеше киләчәктә депрессиягә дә бирешергә мөмкин. Шуңа күрә йокының да чамасын белергә кирәк.

➤Галимнәр, көндез 15–20 минут черем итеп алудан да яхшырак, файдалырак әйбер юк, дип ышандыра. Фәнни телдә ул Штирлиц йокысы дип атала. Көндез 15–20 минут йоклап алган кеше ныклап йоклап китәргә өлгерми, димәк, аңа йокыдан уяну да, көндәлек эшләрен дәвам иттерү дә җиңелрәк булачак. Көн уртасында берәз гына черем итеп алган кеше кичкә кадәр җитәрлек көч, энергия туплый. Кыска вакытлы көндезге йокыдан соң кешенең игътибарлылыгы – 50 процентка, хәрәкәтчәнлеге 16 процентка яхшыра. Моннан тыш көн уртасында черем итеп алган кешенең кәефе дә яхшыра, ярсучанлыгы кими, зиһене ачыла.

➤Төнлә 2–3 сәгатькә азрак йоклаган кеше көндез бер сәгать черем итеп алса да куркыныч түгел. Профессиональ рәвештә спорт белән шөгыльләнгән, көн саен физик күнегүләр ясаган кешегә көндез 40–50 минут йоклап алу хәерле. Шушы вакыт эчендә мускуллар тулысынча ял итәргә өлгерә. Төнлә тиешенчә йокламаган, авыр физик яки акыл хезмәте башкарган кешеләргә, йөкле хатын-кызларга да көндез нәкъ шуның кадәр йоклап алырга киңәш ителә. Көндез черем итеп алырга мөмкинлек булмаса, күзләрне йомган килеш берничә минут ятып яки утырып тору да файдага булачак.

➤Көндез черем итеп алу гадәте чир билгесе дә булырга мөмкин. Аерым алганда, йоклаганда билгеле бер вакыт дәвамында сулыш алмыйча торган (апноэ) кешеләр еш кына көндез дә черем итәргә ярата. Апноэ – бик мәкерле чир. Ул Җир шарында яшәүчеләрнең яртысында диярлек күзәтелә. Көндез черем итеп алу гадәте кешедә нарколепсия башлану турында да кисәтергә мөмкин. Әлеге неврологик тайпылыш вакытында кеше көндез гел йокымсырап йөри.

➤Өлкән яшьтәге кешеләр көндез ешрак йоклый. Яшь барган саен, кешенең тәүлек дәвамындагы активлыгы да кими. 60–65 яшьтән соң кеше, гадәттә, көн уртасында хәлсезлек сизә. Шуңа алар ярты сәгать булса да черем итеп ала. 80–85 яшен тутыручылар исә көндез икешәр тапкыр 30–40 минут йоклап ала.

➤Күпләр көндез йоклап торганнан соң баш авыртудан зарлана. Бу, гадәттә, шул ук апноэдан (йоклаганда сулыш туктап тору) интеккән кешеләрдә күзәтелә. Интернетта бу уңайдан язган башка мәгълүматлар берсе дә дөреслеккә туры килми.

Илдар Мөхәммәтҗанов

КӨНДЕЗ ЙОКЛАУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

1. Көндез черем итеп алу мәҗбүри түгел. Аны организм сораган очракта гына эшләргә кирәк.
2. Көндез 15.00–16.00 сәгатькә кадәр черем итеп алу ягын карагыз. Юкса төнлә йокысызлыктан интегүегез бар.
3. Черем итәр алдыннан телефонызны, йокыгызны бүлә торган башка җиһазларны сүндереп куегыз.
4. Көндезге йокы урыны уңайлы, тыныч булырга тиеш. Караңгылык җитмәсә, йокы өчен махсус битлек, караңгы пәрдә ярдәмгә киләчәк.
5. Сәгатьне 20 минуттан соң шалтырарлык итеп көйләп куегыз.

Сүз уңаеннан

Юкә йокысызлыктан коткара

Юкә себеркесе йокысызлыктан коткара. Мондый себеркене елның салкын вакытында, кешенең организмы кояш һәм витамин җитмәүдән стресс кичергәндә куллану файдалырак. Аның белән чабынып, салкын тию авыруларырын кисәтергә, иммунитетны ныгытырга мөмкин. Мунчадан чыккач, юкә чәе эчү дә шифалы. Юкә себеркесе – бит тиресе өчен дә мәңә дигән чара. Ул аны агарта, яраларны төзәтә, бетчәләрдән, пигмент тапларыннан, сипкелдән коткара.

Экзотик шифа

●**Ананас** – иң билгеле тропик җиләк-җимешләрнең берсе. Аның бавыр, ашказаны-эчәклек тракты, йөрәк чирләреннән, азканлылыктан, нерв тайпылышлары булганда файдасы зур.

●**Папайяны** икенче төрле «кавын агачы» дип йөртәләр. Аның ябыктыру үзлеге бар. Шикәр диабеты белән чирләүчеләрдә ул инсулинга бәйлелекне киметә.

●**Киви** (кытай крыжовнигы) – грипп эпидемиясе вакытында алыштыргысыз. Шулкадәр аскорбин кислотасы бер җиләк-җимештә дә юк. Стресслардан котылырга да ярдәме тия.

●**Личи** – үзенчәлекле җиләк-җимеш. Аның тәме әчкелтем-баллы. Ул кешене дәртләндерә. Шунлыктан личины икенче төрле «мәхәббәт җимеше» дип йөртәләр.

●**Кокос** бавырны чистарта, бөтчәләрне бетерә, матдәләр алмашын яхшырта, тамакны туйдыра. Согы сусауны баса.

●**Лайм** холестерин күрсәткечен төшерә. Аны салатларга, ит, балык ризыкларына кушалар.

●**Питахайя** яки «аждаһа җимеше» йөрәк һәм ашкайнату әгъзалары эшчәнлеген яхшырта.

●**Манго** тиренең торышын яхшырта, җыерчыклар чыгуны кисәтә. Тирене яшь килеш саклыйсыгыз килсә, көненә бер манго ашагыз.

●**Маракуйя** шлакларны чыгара, кан басымын күтәрә, бавыр һәм бөер чирләреннән интегүчеләргә файдалы.

АВГУСТТА НИНДИ ДАРУ ҮЛӘННӘРЕ ҖЫЯРГА?

Дуләнә (боярышник красный) – чәчәкләре, җимешләре
Песи үләне (валериана лекарственная) – тамыры
Күк җиләк (голубика) – җимешләре
Зәңгәр мәтрүшкә (душица обыкновенная) – чәчәкләре
Тырнак гөл (календула лекарственная (ноготки)) – чәчәкләре
Балан (калина обыкновенная) – җимеше, кайрысы
Кычыткан – яфраклары
Әрекмән – тамыры
Кура җиләге – җимеше
Үги ана яфрагы (мать-и-мачеха) – чәчәге, яфрагы
Тузганак (одуванчик лекарственный) – үләне, тамыры
Абага (папоротник мужской) – тамыры
Петрушка – үләне, тамыры
Бака яфрагы (подорожник большой) – яфрагы
Әрем (полынь горькая) – үләне
Ромашка – чәчәк кәрзиннәре
Миләш – җимеше
Нарат – ылысы, бөресе
Дару үләннәре җыю өчен иң кулай көннәр: 2–12 август
Дәвалану өчен үлән тамырларын 16–26 август аралыгында җыеп калу отышлы.

Күз күрүен яхшырту өчен

100 грамм күрәгә өстенә капланырлык итеп кенә яңа кайнап чыккан су салыгыз да 1 сәгать дәвамында төнәтегез. Аннан күрәгәне ваклап турап, шуңа вак итеп уылган кишер һәм 1 аш кашыгы шикәр оны салып, яхшылап болгатыгыз. Бу – бер көнлек микъдар. Әлеге катнашманы бер ай дәвамында ашарга киңәш ителә.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

РОЗА КӨЙСЕЗ ТҮГЕЛ

Хатын-кызлар яраткан патшалар чәчәген һәркем үстерә аламы? Сатып алганда, тәрбияләгәндә нәрсәләрне истә тотарга?

Розалар яратучы, «Ирек мәйданы» газетасында «Бакчачы почмагы» сәхифәсен алып баручы бакчачы-журналист Роза НУРГАЛИЕВА әлеге үзенчәлекле чәчәкне үстерү серләрен ачты.

Озын гомерле чәчәк

Розаларны үзем Роза булган өчен генә түгел, ә җәй буе чәчәктә утырганнары өчен яратам. Күпьеллык чәчәкләр күп мәшәкать тудырмый, һәр яз берьеллык чәчәкләр үстерү өчен ныграк тырышлык кирәк. Әмма һәр бакчачы күпьеллык чәчәкләрнең дәвамлы чәчәк атмавын белә. Мәсәлән, пион, лилия, флоксларның чәчәк атуын түземсезлек белән көтәсең, ә алар ике атнадан коелып бетәләр. Ә розалар кабат-кабат, кара көзгә кадәр чәчәк ата. Алар бер урында 25–30 ел рәхәтләнеп үсә ала, монысы да – зур өстенлек.

Төрен, исемен белү кирәк

Розалар тәрбиягә таләпчән, әмма көйсез түгел. Хәзер кышка чыдам сортлар, төрләре бар. Бары дөрес итеп утыртырга, тиешенчә тукландырырга гына кирәк. Мин үзем питомниклардан, махсус кибетләрдән алырга тырышам. Чиләбе өлкәсеннән кайтарылган розаларым бар. Урал климатында чыныккан розалар бездә яхшы үсә. Шул ук вакытта җирле роза үстерүчеләрдән алганнары да бар. Алары арзанрак, әмма аларның төрен, исемен белмисең. Ә утыртырга урын сайлаганда, моны белү бик мөһим. Җирле роза үстерүчеләр гадәттә гөлҗимешкә ялганган үсентеләр тәкъдим итә. Дөрес утыртмаганда, кышын салкынга бирешкәндә, мондый розаларның кыргыйлану куркынычы бар. Базардан алмагыз, димим, үземнең бер яраткан розам да базардан алынган. Ул ел саен туган көнемә 13–15 чәчәкле букет әзерли. 7–8 ел бер урында үсә, кыргыйланмады. Ә розаларның кыргыйлануы бик еш күзәтелә. Утыртканда исемен, төрен булса да белергә, чөнки кыска сабаклы спрей, җирне каплап үсүче почвопокровный, чәй-гибрид төрләренә күп урын кирәкми. Ә куаклы, флорибунда, үрмәләп үсүче (плетистая) төрләре җәелеп үсәчәк, аларны алдан ук ничек формалаштыру, үрмәләтү турында уйларга кирәк. Соңгы вакытта Канада розаларын үрчетү башладым. Бу төр чәчәкләр Себердә дә үсә ала, капламаган килеш 35 градуслы салкыннарга да бирешмиләр. Чынлыкта, розаларны бездәге суык кышлар түгел, ә ноябрьдәге карсыз салкыннар, эретеп-суытып торучы кышлар һәм язгы көйсез һава торышы харап итә. Көзен тамырлары өшү, язын пешегү куркынычы бар.

Шиңгәнен кисеп тор

Августка кераёбез, розаларның беренче чәчәк ату дулкыны тәмамланып килә, икенче дулкын да ким булмасын дисәгез, шиңгән чәчәкләрен вакытында кисеп торыгыз. Игътибар итсәгез, чәчәк астында 1–2–3 таҗлы яфраклар үсә. Чынлыкта, розаның яфрагы биш таҗлы. Тулы булмаган яфрак өстеннән чәчәк атмаучы ботаклар үсә. Русча аны «слепые ветки» дип әйтәләр, ягъни «сукыр» ботаклар. Безгә тулы биш таҗлы яфракка кадәр төшеп, аннан 1,5 см гына өстәнрәк кыйгачлап кисәргә кирәк. Болай эшләгәндә бик тиздән яшь ботак үсеп чыга һәм чәчәк бөреләре формалаша.

Кышка алдан әзерлән

Розалар суыкларны яхшы чыксын өчен, кышка әзерләргә кирәк. Мин җәйнең икенче яртысыннан азот бирмим, сентябрь азагында барлык чәчәк бөреләрен кисәм. Аңлыйм, бакчаны мөмкин кадәр озаграк чәчәктә тотасы килә, кара көздә матурлыкның кадере тагын да арта. Әмма чәчәк атып хәлсезләнмәсеннәр, ботакларын кышка әзерләсеннәр өчен, бөреләрен кызганмаска кирәк. Көзен бакчада башка чәчәкләр дә җитә.

Көзен розаларны нык кисмим, азрак кыскарту, авыру, карт ботакларын кисү дә җитә. Төпләренә туфрак салып җылытам, бу карсыз ноябрь суыкларында тамырларын саклау өчен кирәк. Розаның ботаклары өшеп, язга каралып чыкса да, казып ташларга ашыкмагыз. Тамырлары нык икән, ул үсеп чыга һәм шул җәйне үк чәчәк тә атачак. Гадәттә, розаларны ак спанбонд белән төрәм. Әмма моны кар оча башлаганда гына эшләргә кирәк, алар беренче суыкларда табигый чыныгу узарга тиеш. Ә язын кар эри башлау белән үк ике яктан һава керерлек итеп ачарга ашыгыгыз.

Куаклы розамны гына капламыйм, кыскартып кисәм генә. Язын каралган ботакларын кисәм, ул яңарып китә. Үрмәләп үсүче фламментанц розам ике елда бакча бизәгенә әверелде. Суыкка бик чыдам, башкалардан аермалы буларак, ул бер тапкыр гына – июнь азагыннан август башына кадәр чәчәк ата. Аннан кышка әзерләнә башлый. Аның ботаклары нечкә, сыгылмалы, астына такта салып, җиргә яткырам һәм спанбонд ябам. Ул шулай кар астында юрган белән кышлый.

Язын салкыннар куркынычы бетү белән бөтенләй ачарга, төбенә өйгән туфрагын алырга һәм 1 процентлы бордо сыекчасы яки ХОМ сибеп йогышсызландырырга кирәк. Язгы санитар кисүне көннәр җылынган, бөреләр бүрткән вакытка калдырыгыз. Чөнки иртә язда ботакның исәнме икәнлеген чамалап булмый.

Тукландыру

1 Азот язын һәм җәй башында гына кирәк. Азотлы ашламалар – мочевина (карбамид) һәм аммиак селитрасы. 1 чиләк суга 1 аш кашыгы мочевина яки аммиак селитрасы кушып сибәргә кирәк. Бу эш, гадәттә, май башында башкарыла.

2 Май азагы – июнь башында чәчәк бөреләре барлыкка килгәндә, розаларның азот кына түгел, фосфор, калийга ихтыяҗы арта. Үзем бу вакытка розалар өчен чыгарылган махсус комплекслы ашламалар алып куям. «Агрикола», «Здравень», «Идеал», «Кемира», «Фертика»ның розалар өчен махсус ашламалары бар. Хәзер ОМУ ашламалар (ягъни органик-минераль ашлама) да чыгарыла. Ул торфтан ясала, гуминлы матдәләргә бай. Аны бүлмә розалары өчен дә кулланырга була. Бәяләре тешләми, чөнки розаларны гектарлап үстермисең бит.

3 Августта чәчәкләргә азот кирәкми, фосфор, калийга ихтыяҗ зур. 1 чиләк суга 1әр аш кашыгы суперфосфат, калий сульфаты, 1 стакан көл кушарга була. Суперфосфат салкын суда эреми, азрак кайнар суда эретеп, кирәк кадәр су кушыгыз.

Өйдәгеләрне – бакчага

Миндә сары һәм алсу төстәге бүлмә розалары да бар. Язын аларны бакчага чыгарам. Сәбәбе гади: бүлмә розалары коры һаваны яратмый, бик еш пәрәвез талпанына бирешә. Өйдә аңа ешрак су бөркергә кирәк. Бакчадан алар көч җыеп, бик матурланып керәләр.

Үрчетү

Розаларны чыбыкчадан үрчетергә була, тик куаклы, үрмәләп үсә торган, ягъни ялганмаган розаларны гына болай үрчетә аласыз. Көзен кискән ботакларын дымлы ком тутырылган чиләккә утыртып, базга төшерергә, мартта уянган ботакларны «Корневин» кебек стимулятор кушылган сулы савытка куеп тамырландырып, чүлмәккә утыртырга була.

Тәмле булсын!

БОРЧАК МАРИНАДЛАУ

Дания Шәрәфиева рецепты

Чистартылган борчакны кайнар суга салып, 3–5 минут кайнатырга. Банкаларга сөзеп тутырырга. Өстенә кайнар маринад коеп, банкаларны су эчендә 8–10 минут кайнатып алырга.

Маринад әзерләү: *1 л суга 1 аш кашыгы тоз, 2 аш кашыгы шикәр комы, 2 аш кашыгы серкә. 1 литр суга ясалган маринад 600 миллилитрлы 4 банкага җитә.*

ТӘМЛЕ ЖЕЛЕ

Лилия Гыйниятуллина рецепты

Кирәк була: *500 г кызыл карлыган, 500 г кура җиләге, 400 г шикәр комы.*

Кызыл карлыганны изеп, иләк яки марля аша согын сыгарга. Аңа шикәр комының яртысын салып кайнатып чыгарырга һәм сүндерергә. Аннары кура җиләгенең өчтән ике өлешен шулай ук изеп, согын чыгарырга. Карлыган өстенә салып, кайнатып чыгарганнан соң, 2–3 минут утта тотарга. Аңа калган кура җиләген өстәп, тагын кайнатып чыгарырга, сүндергәч, калган шикәр комын салып болгатырга. Күбеген җыярга онытмагыз. Аннары кайнар килеш стерильләштерелгән банкаларга тутырып, тимер капкач белән ябарга. Салкын урында сакларга.

Үзем сынадым

КЕЛӘМ ЮАБЫЗ

Үз йортыбыз белән яшәгәнлектән, туфракка теләсә нинди химия эләкмәсен дип, келәмне кер сабыны белән юам. Башта келәмгә җылы су сибәм. Аннары кер сабынын бөтен өслеккә тидереп, мунчала яки щетка белән ышкыйм. Аннары яхшылап су сиптереп чайкап элеп куям. Болай эшләгәндә туфракка да зыян килми, келәм дә ялт итә һәм катып та калмый.

Алсу ЗАРИПОВА. Яшел Үзән

ЧАБУДАН ТАРТМАСЫН

Бурычлы үлмәс, якты көн дә күрмәс, ди халык. Әмма дөнья булгач, бурычка алырга да, бирергә дә туры килә. Хәзерге вакытта бу – бигрәк тә актуаль күренеш. Әҗәт кайчан кайтарылырга тиеш? Кул белән биргән бурычны аяк белән йөреп алмас өчен, нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

Лаеш районындагы «Ихлас» мәчете имамы Мөдәррис хәзрәт ГЫЙМРАНОВ белән шул хакта сөйләштек.

:: Мөдәррис хәзрәт, ислам дине бурычка әйбер алу, бурыч кайтаруга нинди мөнәсәбәттә?

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһиссәләм бер хәдисендә: «Әгәр дә кеше үзе өчен башкалардан сорау, теләнү капкаларын ачса, Аллаһы Тәгалә мәшәкать капкаларын ачар», – ди. Бу кирәксә-кирәкмәсә бурычка әйбер алып тору, башкаларга ялвару, өметләнү кебек күренешләрне гадәткә әверелдергән кешеләргә кагыла. Ибраһим галәйһиссәләмне утка тыккан вакытта фәрештәләр аннан, ярдәм итикме, дип килеп сораганда да ул: «Миңа Аллаһы Тәгаләнең ярдәме җитә», – дигән. Шуңа күрә кешедән бурычка сораган вакытта да безнең иң беренче эшебез – Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорау. Пәйгамбәребез тагын бер хәдисендә: «Бурычны алган вакытта кеше түпле, ихлас кайтару нияте белән ала икән, Аллаһы Тәгалә ул бурычны кайтарырга ярдәм итәр», – ди. Әгәр кеше бурычны алырмын да кайтармам дигән ният белән ала икән, Аллаһы Тәгалә аңа капкаларын ябачак. Шул рәвешле диндә бурычка әйбер алу рөхсәт ителгән. Әмма бу адымга аңа дөрестән дә мохтаж, ул бик кирәк булганда гына барырга кирәк. Бер кирәкмәгәнгә бурычка бату хәерле булмас.

:: Бурыч ничә көндә, айда кайтарылырга тиеш?

– Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә «Нәҗем» сүрәсендә: «Бер-берегез белән килешүләр турында соралырсыз», – ди. Бүген бу – аеруча мөһим, актуаль мәсьәлә. Бурычны алган вакытта бирүче һәм алучы ничек килешәләр, әҗәт шул рәвешле һәм шул вакыт эчендә кайтарылырга тиеш. Әйтик, әгәр кеше: «50 мең сум акча алып торам, ай саен 5 мең сум түлим», – дип вәгъдә бирсә, бурычны тулысынча кайтарырга мөмкинлеге булса да, аны килешенгәнчә түләп тора ала. Бурычны җай чыгу белән шундук кайтарам дигән булса, монысы – икенче мәсьәлә. Бу урында шунысын да искәртергә кирәк: начар, гөнаһлы әйбер, гамәлләр, дингә

Август аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Дүш	01:47	03:47	17:13	19:50	21:20
2	Сиш	01:49	03:49	17:12	19:48	21:18
3	Чәрш	01:51	03:51	17:11	19:46	21:16
4	Пәнҗ	01:53	03:53	17:10	19:44	21:14
5	Җом	01:55	03:55	17:08	19:42	21:12
6	Шим	01:57	03:57	17:07	19:40	21:10
7	Якш	01:59	03:59	17:06	19:38	21:08
8	Дүш	02:01	04:01	17:04	19:35	22:05
9	Сиш	00:18	04:03	17:03	19:33	22:00
10	Чәрш	00:31	04:04	17:01	19:31	21:56
11	Пәнҗ	00:41	04:06	17:00	19:29	21:52
12	Җом	00:49	04:08	16:58	19:27	21:47
13	Шим	00:57	04:10	16:57	19:24	21:43
14	Якш	01:03	04:12	16:55	19:22	21:39
15	Дүш	01:09	04:14	16:54	19:20	21:35
16	Сиш	01:15	04:16	16:52	19:17	21:31
17	Чәрш	01:20	04:18	16:51	19:15	21:27
18	Пәнҗ	01:26	04:20	16:49	19:13	21:23
19	Җом	01:30	04:22	16:47	19:10	21:19
20	Шим	01:35	04:24	16:46	19:08	21:15
21	Якш	01:40	04:26	16:44	19:05	21:12
22	Дүш	01:44	04:28	16:42	19:03	21:08
23	Сиш	01:48	04:30	16:40	19:00	21:04
24	Чәрш	01:52	04:32	16:38	18:58	21:01
25	Пәнҗ	01:56	04:34	16:37	18:55	20:57
26	Җом	02:00	04:35	16:35	18:53	20:53
27	Шим	02:04	04:37	16:33	18:50	20:50
28	Якш	02:07	04:39	16:31	18:48	20:46
29	Дүш	02:11	04:41	16:29	18:45	20:43
30	Сиш	02:14	04:43	16:27	18:43	20:39
31	Чәрш	02:18	04:45	16:25	18:40	20:36

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

каршы килә торган әйберләр өчен бурычка бирергә ярамый. Кешенең әҗәтне нинди максатта файдалану өчен алуын белмәгән вакытта, гөнаһы бурычка алучының үзенә булачак.

:: Бурычны вакытында кайтармау гөнаһ саналамы?

– Бурычка бирү – бик зур савап. Ник дигәндә, кеше бу адымга, гадәттә, авыр хәлдә калганда, ниндидер җитди мәсьәләне хәл итәргә кирәк булганда бара. Әҗәтне бер сәбәпсез вакытында кайтармау гөнаһ санала. Әгәр әҗәтне алыр вакыт җитеп тә, бурычны алган кеше аны кайтара алмаса, бирүче исә, аның хәленә кереп, вакытны чигерсә, Аллаһы Тәгалә чиксез күп әҗер бирер. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһиссәләм бер хәдисендә: «Кем дә кем үзенең мөселман кардәшенең мәсьәләсен, дөнья мәшәкатен чишәргә ярдәм итсә, Аллаһы Тәгалә аның үзенең мәсьәләсен чишәр», – ди. Шуңа күрә дустыңа, туганыңа, кардәшеңә ярдәм иткән вакытта аңа ярдәм итәм дип түгел, үзеңә булышам дип уйларга кирәк. Әгәр кеше Аллаһы ризалыгы өчен кешенең бурычын гафу итә ала икән, Аллаһы Тәгалә каршында чиксез күп савапка ирешә. Бурычны кайтару вакытын кичектереп тору да савап.

:: Бүген күпләр кирәкле әйберен кредитка алып яши. Бер уйласаң, бу шулай ук бурычка алу белән бер. Дин кредитка әйбер алуга ничек карый?

– Кредитка әйбер алу белән бурычка алу бер түгел. Ник дигәндә, биргән акчаны арттырып алу – хәрам. Пәйгамбәребез: «Риба (процент) белән кергән бер динар акча уналты зинага тиң», – ди. Шуңа күрә акчаны алып, аны арттырып түләү динебездә бик зур гөнаһ санала. Аллаһы Тәгалә моны тыйды. Икенчедән, безнең бу дөньядагы максат – Аллаһы Тәгаләне риза итәрлек гомер кичереп, Аллаһы рәхмәте белән җәннәтле булу. Күпләр торыр җирем юк, кредитка фатир алам, ди. Әмма без бу дөньяга гомерлеккә килмәгән бит. Мөмкинлегең юк икән, фатирны арендалап тор, яисә әлегә авылга кайтып яшә. Моны кеше иманы, дине булган вакытта гына аңлый.

:: Үлгән кешенең бурычларын кем түләргә тиеш?

– Кайбер төбәкләрдә бер шарт үтәлеп бетми. Кеше үлгәч, аның өстендә берничә бурыч (юу, кәфенләү, җеназасын уку һәм ләхет алынган каберә күмү) бар. Җеназа укып бетергәч, имам яхшы кеше идеме, дигәннән соң: «Бу кешенең бурычлары юкмы?» – дип сорый. Бурычка биргән кеше шунда әйтергә тиеш. Юкса бу дөньядан бурычлы килеш китү, мәрхүмгә кабердә караңгылык, бер газап булачак. Мәрхүмнең бурычлары калган булса, аны туганнары күтәрергә тиеш. Шуңа күрә вакытлыча килгән шушы дөньяда әҗәтләргә чумып, кешедән калышмыйм дип дөнья куарга кирәкми. Бу дөньядагы бурычлар теге дөньяда кыймммәткәрәк төшәчәк.

:: Кеше исән чакта аңа бурычыңны кайтарып өлгерә алмасаң, ни эшләргә?

– Әйткәнемчә, әҗәткә алган, биргән вакытта да килешүне дөрес төзергә кирәк. Кешегә бурычны үзе исән чакта кайтара алмау очрагы да әнә шунда хәл ителергә тиеш. «Бурычны миңа булмаса, минем тормыш иптәшемә, балаларыма кайтарырсың, яисә аны хәйрия итеп башка җиргә күчерерсең», – дип алдан әйтеп, килешеп куярга кирәк. Шуңа күрә үзе исән чакта кешегә бурычын кайтарып өлгерә алмаган очракта аның тормыш иптәше, балалары, якыннарына мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Әти-әни баласына бурычка акча биреп, тегесе кире бирмәсә, гөнаһ буламы?

– Әйе, гөнаһ була. Әти-әни акчаны кире кайтармау шарты белән биргән булса, бер хәл. Әгәр кире кайтару шарты белән, вакытлыча биргән икән, бу гөнаһ булачак.

Бөтен эшләрдә ярдәм итә торган дога

Сөекле пәйгамбәребез: «Һәркем сәхәрдә 7 тапкыр вә ахшамда 7 мәртәбә бу доганы укыса, дөнья вә ахирәткә бәйле бөтен эшләрендә Аллаһы аңа ярдәм бирер», – дигән. «Хәсбийә-ллаалу ләә иләәһә илләә һүүә галәйһи тәүәккәльтү үә һүүә Раббун галәйһә газыйм»

Мәгънәсе: «Аллаһы минем ышанычым, Аның үзеннән башка берниндиилаһи зат юк, мин Аңа тәвәккәлләдем һәм Ул – биек һәм бөек булучы Раббым».

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Лилия ГЫЙМАЗОВА

БЕР ДУСТЫМ БАР...

30 июльдә Халыкара дуслар көне билгеләп үтелә. Шул уңайдан «Ни хәл?» сәхифәсе кунакларыннан балачак дуслары турында сораштык. Сабый чакта дуслык ничек сыналган? Балачак дуслары белән бүген дә аралашамы алар?

«КОНЦЕРТ КУЕП, ТУҢДЫРМАЛЫК АКЧА ЭШЛИ ИДЕК»

Гүзәл ГАЛИУЛЛИНА,
Тинчурин театры артисты:

– Без яшәгән урам шундый киң иде. Балалар күп булгач, иртәдән алып кичкә кадәр гөрләп торды ул. Җыелышып, пионербол, йөзек салышлы уйный идек. Бигрәк тә истә калганы – үзебез оештырган концертлар. Дус кызым Даша безнең каршыдагы йортта яшәде. Аның белән иҗади номерлар уйлап табып, матур итеп билетлар ясап, концертка әзерләнә идек. Аннан шул билетларны күршеләргә сата идек. Ул акчага туңдырма алып ашаган чаклар әле дә исемдә. Дуслык шунда сыналгандыр инде. Аны бит ул чакта уйлап, аңлап бетермисең. Даша – әле дә иң якын кешеләремнең берсе.

«НИ ГЕНӘ КЫЛАНМАДЫК...»

Фирдүс ТЯМАЕВ,
Татарстанның атказанган артисты:

– Без бик шук идек. Бригадир Наил абыйдан качып, борчак басулар, әти-әнидән качып, су коенулар, күрше авылга барулар, үсә төшкәч, әтинең «матае»нда җилдерүләр... Ни генә кыланмадык инде. 10 яшьләр булгандыр, күрше малае белән, мунча артына качып, тәмәке тартып карадык. Тегенең әтисе күрде бит моны, күршегә шунда ук чыбыркы эләкте. Өйгә кереп, нидер эшләп йөргән арада, күрше абый кереп, теге чыбыркыны әтигә тоттырды да, миңа да өлеш чыкты. Дустым Илфат белән «сәпид»тә күрше авылга су коенырга барган көн дә истә. Кайткан чакта яңгырга эләктек. Юлдан түгел, басудан кайта идек җитмәсә. Капка төбенә җиткәндә иртәнге өчләр булгандыр. Ул арада әниләр бөтен авылны аякка бастырган икән. Әтинең, чүмеч белән су сибә-сибә: «Су коенасың килдеме?» – дигәннәре әле дә истә. Дуслык урамга урам каршы сугышканда, бер-беребезне яклаганда сыналгандыр ул. Балачак дусларым белән бүген дә аралашам, бер-беребезне күз карашыннан аңлыйбыз. Сыналган, әмма сынмаган дуслык бит ул!

«САЗЛЫКТА СӘПИТ ЮДЫК»

Ильяс ШӘРИПОВ,
баянчы:

– Футбол тибүләр, «сәпид»тә җилдерүләр, капка төбендә утырулар – болар һәркемгә таныш хәлләрдер инде. Минем дә балачак шулайрак узды. Җәй саен әнинең туган ягына – Кукмара районының Вахит авылына кайта идем. 5–6 яшьләр булды микән, Ринат исемле малай белән дуслашып киттек. Берсендә «сәпид»ләребезне юарга уйладык. Уйладык та сазлыкка төшеп киттек. Аның сазлык икәнен белә идек тә инде югыйсә. Колготки, аның өстеннән шортик, аякта – сандали. Шул килеш кергәнмен дә киткәнмен шул баткаклыкка. Ләкин ничек тә өйгә кайтырга кирәк бит инде. Җитмәсә, бер йортта ремонт ясыйлар иде, минем туган абый да шул тирәдә күренде. Әһә, мин әйтәм, моның күзенә күренмәскә кирәк, кое артына качып торыйм әле. Күпме вакыт узгандыр, әби эзләп табып, алып менеп китте. Кызганыч, балачак дусларым белән инде аралашмыйбыз. Гомумән, чын дуслыкның ни икәнен 20 яшьтән соң, калага күчкәч кенә аңладым.

Ә СИН ТАНЫЙСЫҢМЫ?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

Газетабызның узган санында чыккан җырчы һәм җырларны беренчеләрдән булып Арчадан ***Зәлия*** *ханым танып алды. Афәрин! Бүләк – хуҗасында. Ә рәсемнәр астына без Айдар Галимов башкаруындагы «Җырлыйм туган якта», Зөһрә Шәрифуллинаның «Озак торды атым чапмады» һәм «Казан егетләре» төркеме репертуарыннан «Ак чәчәкләр» җырларын яшергән идек.*

Кайгы-хәсрәтләр, заманның кырыс җилләренә карамастан, күңеле каралмаган аның. Бу дөньяда әнә шул хис булганда, өмет тә өзелмәс, диелә җырда.

Таң җилендә талгын гына тибрәлә торган, зифа, ефәктән киенгән агачлар һәм... мәхәббәт турында бу җыр.

Бу җыр адашып йөргән пар турында. Ул синең хисләр утында янганыңны күзләреңнән үк күрә, ә син сизми дип уйлыйсың.

3 август | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия» 6+
14.15 «Территория Мира» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем…» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 6+
21.00 «Соотечественники» 12+
23.50 «Соотечественники». Роальд Сагдеев. О времени и о себе 12+
00.15 «Рыцари вечности». Г.Исхаки 12+
00.30 «Фолиант в столетнем переплете». Редкое турецкое издание Всемирного атласа 12+
00.40 «Җырлыйк әле!» 6+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
05.50 Татарстан хәбәрләре 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40 «Әй, язмыш, язмыш…» 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» 12+
10.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Илдар Кыямов турында телеочерк 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
19.35 «Татарлар» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
23.05 «Әй, язмыш, язмыш…» 12+
00.40 «Татарлар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» 12+
04.15 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Илдар Кыямов турында телеочерк 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «ОТЧИМ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.45 «Большая игра« 16+
00.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан.
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
23.55 Мария Андреева, Евгений Цыганов, Надежда Маркина, Пётр Зайченко, Борис Невзоров. «СОФИЯ» 16+
01.05 Екатерина Кузнецова, Владимир Жеребцов, Леонид Громов, Александр Самойленко, Екатерина Васильева, Борис Галкин. «КОРОЛЕВА БАНДИТОВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.35, 14.55, 18.50 Новости
06.05, 15.00, 18.05, 22.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.40, 00.50 Специальный репортаж 12+
09.20 «КРЮК» 16+
11.10 Матч! Парад 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00 «ПОБЕГ» 16+
15.40 Хоккей. «Лига Ставок Sochi Hockey Open». СКА (Санкт-Петербург) – «Динамо» (Минск). Прямая трансляция
18.55 Лёгкая атлетика. Чемпионат России. Прямая трансляция из Чебоксар
23.00 «След Пираньи». Телевизионный сериал. Россия, 2014 г. 16+
01.10 Футбол. Южноамериканский Кубок. 1/4 финала. «Сан-Паулу» (Бразилия) – «Сеара» (Бразилия). Прямая трансляция
03.15 Новости 0+
03.20 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. Обзор тура 0+
03.50 Профессиональный бокс. «Короли нокаутов». Хусейн Байсангуров против Манука Диланяна. Трансляция из Москвы 16+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.50 Остросюжетный сериал «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
21.40 Премьера. Остросюжетный сериал «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ» (S) 16+
00.00 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
02.05 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.25 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.30 «Порча». «Рог изобилия» 16+
14.00 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «МОЯ ЧУЖАЯ ДОЧКА» 16+
19.00 «СКАЖИ ТОЛЬКО СЛОВО» 16+
22.45 «Порча» 16+
23.20 «Знахарка» 16+
23.50 «Верну любимого» 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.10 «Тест на отцовство» 16+
02.50 «Давай разведёмся!» 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «БАТЯ» 16+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 00.40 «ЖИВЕТ ТАКОЙ ПАРЕНЬ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «ЧИСТАЯ ПРОБА» 16+
18.50 «Битва оружейников». Док. сериал. «Противотанковые ружья» 16+
19.40 «Секретные материалы». Док. сериал. «Люди Х». Тайный фронт технической разведки» 16+
22.55 «КОМАНДИР КОРАБЛЯ» 12+
02.15 «В НЕБЕ «НОЧНЫЕ ВЕДЬМЫ» 12+
03.35 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА» 12+

4 август | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК 2» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
14.15 «Женское счастье» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 0+
16.00 «Казаннан – казанга» 12+
18.00 «Юлчы» 6+
19.00, 20.00, 01.10 «Точка опоры» 16+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Мажит Гафури. Я сын татарского народа 12+
00.40 «Рыцари вечности». Е.Боратынский 12+
00.55 «Фолиант в столетнем переплете». Цельногравированные издания 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
04.45 «Башваткыч» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БиТ шоу» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Рухының – үз күге». Татарстанның халык язучысы Равил Фәйзуллин турында телеочерк 6+
15.30 «Халкым минем» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
19.35 «Татарлар» 12+
20.00 «Рухының – үз күге». Татарстанның халык язучысы Равил Фәйзуллин турында телеочерк 6+
23.05 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
00.40 «Татарлар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» 12+
04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «ОТЧИМ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.45 «Большая игра» 16+
00.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
23.55 Мария Андреева, Евгений Цыганов, Надежда Маркина, Пётр Зайченко, Борис Невзоров. «СОФИЯ» 16+
01.05 Екатерина Кузнецова, Владимир Жеребцов, Леонид Громов, Александр Самойленко, Екатерина Васильева, Борис Галкин. «КОРОЛЕВА БАНДИТОВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.35, 14.55, 20.55 Новости
06.05, 15.00, 18.05, 22.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.40, 00.45 Специальный репортаж 12+
09.20 «СЛЕД ПИРАНЬИ» 16+
11.10 Матч! Парад 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00 «ПОБЕГ» 16+
15.40 Хоккей. «Лига Ставок Sochi Hockey Open». СКА (Санкт-Петербург) – «Адмирал» (Владивосток). Прямая трансляция
18.20 Лёгкая атлетика. Чемпионат России. Прямая трансляция из Чебоксар
21.00 Смешанные единоборства. UFC. Джулианна Пенья против Аманды Нуньес. Сергей Павлович против Деррика Льюиса. Трансляция из США 16+
23.00 «МОЛОДОЙ ИП МАН: КРИЗИСНЫЕ ВРЕМЕНА« 16+
01.05 Пляжный футбол. Женщины. Россия – Белоруссия 0+
02.20 «Игорь Численко. Удар форварда». Док. фильм 12+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 Сериал «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.50 Остросюжетный сериал «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
21.40 Премьера. Остросюжетный сериал «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ» (S) 16+
00.00 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
02.00 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.25 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.30 «Порча». «Маленькая девочка» 16+
14.00 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «МЕНЯ ЗОВУТ САША» 16+
19.00 «ИЗ СИБИРИ С ЛЮБОВЬЮ» 16+
22.30 «Порча» 16+
23.00 «Знахарка» 16+
23.35 «Верну любимого» 16+
00.05 «Понять. Простить» 16+
01.00 «Тест на отцовство» 16+
02.40 «Давай разведёмся!» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «ЧИСТАЯ ПРОБА» 16+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.25, 00.20 «ЛЮБОВЬ ЗЕМНАЯ» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «ЧИСТАЯ ПРОБА» 16+
18.50 «Битва оружейников». Док. сериал. «Противотанковые САУ» 16+
19.40 «Код доступа». «Гитлер. Пациент №1 Третьего Рейха» 12+
22.55 «НАГРАДИТЬ (ПОСМЕРТНО)» 12+
01.55 «ПРИЗРАК И ТЬМА» 16+
03.40 «ШЕЛ ЧЕТВЕРТЫЙ ГОД ВОЙНЫ…» 12+
05.05 «Вторая мировая война. Возвращая имена». Док. фильм 12+

5 август | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 15.15 «УЕННАН УЙМАК 2» 12+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Классный час» 12+
14.45 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
17.00 «Бәллүр каләм – Хрустальное перо-2022». Прямая трансляция церемонии награждения победителей Республиканского журналистского конкурса 0+
19.00 «Болгар радиосы» концерты 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Юлчы» 6+
23.00 «ЛЮБОВЬ БЕЗ ПЕРЕСАДОК» 16+
00.40 «Рыцари вечности». Н.Дурова 12+
00.55 «Фолиант в столетнем переплете». Галерея моды 12+
01.10 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ». Телефильм 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Ком сәгате» 12+
09.40, 15.30 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Әдәби галәмгә тәрәзә…» Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин турында телеочерк 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.30 «Калеб» 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Туган җир» 12+
19.35 «Заман көзгесе» 6+
20.05, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.40 «Калеб» 6+
01.05 М.Гыйләҗев. «БАЛА БАЛАСЫ БАЛДАН ТАТЛЫ». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 «Две звезды. Отцы и дети». Финал (S) 12+
23.40 «Двое. Рассказ жены Шостаковича» 12+
01.45 «Информационный канал» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Владимир Вдовиченков, Павел Деревянко, Александр Самойленко, Мария Миронова, Оксана Фандера, Александр Ратников, Виталий Хаев, Игорь Угольников, Артур Ваха, Никита Панфилов. «САЛЮТ-7» 12+
23.30 Владимир Машков, Александр Балуев, Андрей Панин, Александр Голубев, Юрий Беляев. «КАНДАГАР» 16+
01.25 Фёдор Бондарчук, Сергей Бондарчук, Владимир Яглыч, Светлана Ходченкова, Александр Балуев, Мария Андреева. «ВОИН» 12+
02.55 Даниил Спиваковский, Андрей Кузичев, Светлана Тимофеева-Летуновская, Елена Захарова, Александр Семчев. «МОЛЧУН» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.35, 14.55, 20.10 Новости
06.05, 15.00, 20.15, 23.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 Специальный репортаж 12+
09.20 «СЛЕД ПИРАНЬИ» 16+
11.10 Матч! Парад 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.40 «Лица страны. Ольга и Евгения Фролкины» 12+
13.00 «ПОБЕГ» 16+
15.55 Лёгкая атлетика. Чемпионат России. Прямая трансляция из Чебоксар
18.55 Пляжный футбол. Женщины. Россия – Белоруссия. Прямая трансляция
20.55 «РецепТура» 0+
21.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Айнтрахт» – «Бавария». Прямая трансляция
00.15 «УЛИЧНЫЙ БОЕЦ: КУЛАК УБИЙЦЫ» 16+
02.20 «Виктор Царёв. Капитан великой команды». Док. фильм 12+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.50 Остросюжетный сериал «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
21.45 Премьера. Дмитрий Клепацкий, Виктория Полтарак. «ЛОВУШКА» (S) 16+
23.25 Премьера. «Живи спокойно, страна!» Концерт Ларисы Рубальской (S) 12+
01.10 «Их нравы» 0+
01.25 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.25 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.30 «Порча». «Наследство» 16+
14.00 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «СКАЖИ ТОЛЬКО СЛОВО» 16+
19.00 «ОТПУСК В СОСНОВОМ ЛЕСУ» 16+
22.45 «Порча» 16+
23.20 «Знахарка» 16+
23.50 «Верну любимого» 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.10 «Тест на отцовство» 16+
02.50 «Давай разведёмся!» 16+

ЗВЕЗДА

05.35 «ЧИСТАЯ ПРОБА» 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 23.50 «СУДЬБА» 16+
12.30, 19.00 «Освобождение». Док. сериал 16+
13.25 «Специальный репортаж» 16+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
14.15 «ВИКИНГ» 16+
18.40 «Время героев». Премьера! 16+
19.30 «ЗОЛОТАЯ МИНА» 12+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.00 «Музыка+» 12+
02.35 «НАГРАДИТЬ (ПОСМЕРТНО)» 12+

6 август | Шимбә

ВГТРК ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам». Музыкаль котлаулар 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Гүзел Гайнуллина 12+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Татар халык җырлары» 0+
11.30 «Казаннан – казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Әсхәт Хисмәтовның 70 яшьлек юбилей кичәсе» 6+
16.00 «Туган җир» 12+
16.30 «Цирк завтрашнего дня». Цирковое шоу юных артистов 6+
18.00 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Соотечественники» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «Кунак БиТ шоу» 12+
23.00 «ОДНОКЛАССНИЦЫ» 16+
00.20 «ОДНОКЛАССНИЦЫ. НОВЫЙ ПОВОРОТ» 16+
01.40 «Вехи истории». И пером, и штыком 12+
02.05 «Каравай». Гырон Быдтон 6+
02.30 «Цирк завтрашнего дня» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Бормалы су. З.Хәбибуллин» 6+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Башваткыч» 12+
12.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 М.Гыйләҗев. «Казан егетләре». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
17.10 «Казаннан – казанга» 12+
17.45 «Халкым минем» 12+
18.15 «Башваткыч» 12+
19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 Татарстанның халык артисты Зөфәр Хәйретдиновның 60 яшьлек юбилей кичәсе 6+
23.20 «Тукран тәүбәсе». «Мунча ташы» татар эстрада театры спектакле 16+
02.20 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Татар җыры – йөз ел элек» 6+
03.00 «Башваткыч» 12+
03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.05 «Халкым минем» 12+
05.30 «Нәсыйхәт» 6+

1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.45 «Слово пастыря» (0+)
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «Поехали!» 12+
11.10 «Видели видео?» (0+)
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» (0+)
13.40 Ко Дню Воздушно-десантных войск. Борис Галкин, Михай Волонтир. «В ЗОНЕ ОСОБОГО ВНИМАНИЯ» 12+
15.35 Фильм Юрия Озерова «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «НАПРАВЛЕНИЕ ГЛАВНОГО УДАРА» (S) 12+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 «На самом деле» 16+
19.25 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.15 К 85-летию Андрея Кончаловского. Фильм «ПЕРВЫЙ УЧИТЕЛЬ» 12+
01.10 «Наедине со всеми» 16+
03.00 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
12.00 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
13.05 Ольга Кавалай-Аксёнова, Артём Осипов, Валерия Бурдужа, Василий Шмаков, Александр Кузнецов. «Я ВСЁ ПОМНЮ» 12+
17.00 Вести
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести
21.00 Наталья Бардо, Кирилл Запорожский, Татьяна Васильева, Владислав Ветров, Никита Зверев. «ВТОРОЙ ШАНС» 12+
00.50 Глафира Тарханова, Елена Дробышева, Сергей Мухин, Анатолий Котенев, Ольга Сухарева и Александра Флоринская-Будунова. «ЛУЧШИЙ ДРУГ СЕМЬИ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Майк Ветрила против Сиримонгхона Ламтуана. Трансляция из Таиланда 16+
07.00, 08.55, 12.40, 16.10 Новости
07.05, 12.45, 14.40, 16.15, 19.30, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 «МОЛОДОЙ ИП МАН: КРИЗИСНЫЕ ВРЕМЕНА» 16+
10.45 «Рэмбо. Первая кровь» 16+
13.25 Пляжный футбол. PARI Чемпионат России. «Спартак» (Москва) – «Дельта» (Саратов). Прямая трансляция
14.55 Пляжный футбол. PARI Чемпионат России. «Локомотив» (Москва) –«Кристалл» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
17.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. ЦСКА – «Факел» (Воронеж). Прямая трансляция.
19.50 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. «Краснодар» – «Локомотив» (Москва). Прямая трансляция
22.45 «НОКДАУН» 16+
01.40 Футбол. Чемпионат Германии. «Боруссия» (Дортмунд) – «Байер» 0+
03.40 Новости 0+
03.45 Прыжки в воду. Матч ТВ Кубок Кремля 0+
05.00 Смешанные единоборства. UFC. Тиаго Сантос против Джамала Хилла. Прямая трансляция из США

НТВ

04.35 Остросюжетный сериал «ДЕЛЬТА» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» (S) 0+
09.25 «Едим дома» (S) 0+
10.20 «Главная дорога» (S) 16+
11.00 «Живая еда» с Сергеем Малозёмовым (S) 12+
12.00 «Квартирный вопрос» (S) 0+
13.05 «Однажды...» (S) 16+
14.00 «Своя игра» (S) 0+
15.00 «Следствие вели...» 16+
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.35 Остросюжетный сериал «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
22.30 «Маска» (S) 12+
01.30 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.50 «СВАТЬИ» 16+
08.40 «МИЛЛИОНЕР» 16+
10.45 «ПОД КАБЛУКОМ». 1-я – 8-я серии 16+
18.45 «Скажи, подруга» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК». 121-я и 122-я серии 16+
22.40 «БЕЛОЕ ПЛАТЬЕ» 16+
00.35 «ПОД КАБЛУКОМ». 1-я – 4-я серии 16+
04.00 «Преступления страсти» 16+
05.35 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.30, 02.25 «КОЛЬЦА АЛЬМАНЗОРА» 6+
06.30, 08.15, 23.50 «ВО БОРУ БРУСНИКА» 12+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.35 «Легенды кино». Юрий Соломин 12+
10.15 «Главный день». Майя Булгакова 16+
11.00 «Война миров». Док. сериал. «Битва танковых асов» 16+
11.45 «Не факт!» 12+
12.15 «СССР. Знак качества» с Гариком Сукачевым. «Печки, лавочки... Как жила советская деревня?» 12+
13.15 «Легенды музыки». Игорь Тальков 12+
13.40, 18.25 «С ЧЕГО НАЧИНАЕТСЯ РОДИНА» 16+
21.55 «ДУША ШПИОНА» 16+

7 август | Якшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Яшәү яме». Сиринә Зәйнетдинова 6+
08.00 «Адымнар» 12+
08.30 «Туган авылым» 6+
08.45 «Эти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык». Роза Әхмәдиева 12+
11.00 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Галиҗанап шагыйрь». Илдар Юзеев 6+
13.30 Марат Мухин хитлары 6+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 «Соотечественники» 12+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Айрат Хаметов 12+
22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
23.00 «ЧТО ГЛОЖЕТ ГИЛБЕРТА ГРЕЙПА» 16+
01.00 «Вехи истории». Время надежд 12+
01.25 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
05.50 Татарстан хәбәрләре 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Лирон Хәмидуллин турында телеочерк 6+
07.00 «Очрашулар эзләп». Габделфәт Сафин концерты 6+
09.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
10.00 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Туган авылым» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 М.Гыйләҗев. «ТАГЫН КАЗАН ЕГЕТЛӘРЕ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
15.05 «Йөрәк җылысы». Филүс Каһиров концерты 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
21.10 «Өмет йолдызы». Эльмира Кәлимуллина концерты 6+
22.45 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
23.45 «Ком сәгате» 12+
00.40 «Яшьләр тукталышы» 12+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
02.50 «Татар сүзе» II Халыкара бәйгесенең гала-концерты 6+
05.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Бормалы су. З.Хәбибуллин» 6+

1 КАНАЛ

05.05, 06.10 Анна Банщикова, Анна Снаткина. «ОТЧАЯННЫЕ» (S) 16+
06.00 Новости
07.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.45 «Часовой» (S) 12+
08.15 «Здоровье» 16+
09.20 «Непутевые заметки» с Дм. Крыловым 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Специальный репортаж. «Парни с Квартала» 16+
11.20 Анатолий Васильев, Елена Проклова, Дмитрий Миллер, Борис Щербаков. «АНДРЕЕВСКИЙ ФЛАГ» (S) 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «АНДРЕЕВСКИЙ ФЛАГ» 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 «АНДРЕЕВСКИЙ ФЛАГ» 16+
21.00 «Время»
22.35 «Выбор агента Блейка» 12+
00.45 «Наедине со всеми» 16+
02.35 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.35 Анна Невская, Константин Соловьёв, Анна Банщикова. «ПОЛЫНЬ ТРАВА ОКАЯННАЯ» 12+
07.15 «Устами младенца»
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым»
09.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
12.00 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
13.05 Ольга Кавалай-Аксёнова, Артём Осипов, Валерия Бурдужа, Василий Шмаков, Александр Кузнецов. «Я ВСЁ ПОМНЮ» 12+
17.00 Вести
18.00 Премьера. «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести
22.00 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Мария Куликова, Григорий Антипенко и Иван Стебунов. «ДОПУСТИМЫЕ ЖЕРТВЫ» 16+
02.35 Анна Невская, Константин Соловьёв, Анна Банщикова. «ПОЛЫНЬ ТРАВА ОКАЯННАЯ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. UFC. Тиаго Сантос против Джамала Хилла. Прямая трансляция из США
08.00, 09.25, 12.25, 14.55 Новости
08.05, 12.30, 15.00, 18.05, 19.40, 23.10 Все на Матч! Прямой эфир
09.30 «НОКДАУН» 16+
12.55 Регби. PARI Чемпионат России. «Стрела» (Казань) – «Локомотив-Пенза». Прямая трансляция
15.40 Хоккей. «Лига Ставок Sochi Hockey Open». СКА (Санкт-Петербург) – «Авангард» (Омск). Прямая трансляция
18.25 Пляжный футбол. PARI Чемпионат России. «Локомотив» (Москва) – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
19.55 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. «Сочи» – «Пари НН» (Нижний Новгород). Прямая трансляция
22.00 После футбола с Георгием Черданцевым
23.00, 03.40 Новости 0+
00.05 VII Международные спортивные игры «Дети Азии». Церемония закрытия. Трансляция из Владивостока 0+

НТВ

04.35 Остросюжетный сериал «ДЕЛЬТА» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу (S) 12+
10.20 «Первая передача» (S) 16+
11.00 «Чудо техники» (S) 12+
12.00 «Дачный ответ» (S) 0+
13.00 «НашПотребНадзор» (S) 16+
14.00 «Своя игра» (S) 0+
15.00 «Следствие вели...» 16+
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.50 Остросюжетный сериал «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
22.40 «Маска» (S) 12+
01.25 «Их нравы» 0+
01.50 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «СВАТЬИ» 16+
09.45 «БЕЛОЕ ПЛАТЬЕ» 16+
11.40 «ИЗ СИБИРИ С ЛЮБОВЬЮ» 16+
15.15 «ОТПУСК В СОСНОВОМ ЛЕСУ» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК». 123-я и 124-я серии 16+
22.40 «МИЛЛИОНЕР» 16+
00.40 «ПОД КАБЛУКОМ». 5-я – 8-я серии 16+
04.00 «Преступления страсти» 16+
06.25 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

06.00 «ПОСТАРАЙСЯ ОСТАТЬСЯ ЖИВЫМ» 12+
07.10 «КОМАНДИР КОРАБЛЯ» 12+
09.00 Новости дня 16+
09.15 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
09.30 «7 августа – День железнодорожных войск». Док. фильм. Премьера! 16+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Спецвыпуск №13» 16+
11.25 «Код доступа». «ВОЗ. Бизнес на здоровье» 12+
12.10 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Евгений Ледин 12+
12.55, 01.15 «Освобождение». Док. сериал 16+
13.25 «Специальный репортаж» 16+
14.30 «ВИКИНГ-2» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.45 «Легенды советского сыска». Док. сериал 16+
22.50 «ЗОЛОТАЯ МИНА» 12+
01.45 «С ЧЕГО НАЧИНАЕТСЯ РОДИНА» 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 1 август

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Мостай Карим. «Озын-озак балачак». Моноспектакль. 1-2 өлешләр
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 2 август

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.20 «Вместе за безопасность»
18.30 Камера музыкасы концерты

Чәршәмбе, 3 август

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 «Вместе за безопасность»
7.20 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
11.40 Прокуратура разъясняет
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Шакир Мәҗитов әсәрләре

Пәнҗешәмбе, 4 август

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 Зөләйха Хисмәтуллина һәм Фәйзулла Туишев язмалары

Җомга, 5 август

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Доброе братство лучше богатства» (на чувашском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 «Җырларыбыз сиңа, игенче». Концерт

Шимбә, 6 август

8.10 Хәйдәр Бигичев иҗатына багышланган концерт-очерк
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Язучылар – балаларга»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Әмирхан Еники. «Йөрәк сере». Радиопостановка

Якшәмбе, 7 август

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10, 16.10 Галиәсгар Камал. «Безнең шәһәрнең серләре». Радиотамаша. 1-2 өлешләр

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Самоховым Александром Сергеевичем (420107, РТ, г. Казань, ул. Марселя Салимжанова, д.14, пом.1; 6238322@mail.ru; тел.: 89178883476, № квалификационного аттестата 16-12-546) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:16:190101:247, площадью 1800 кв. м., расположенного по адресу: Республика Татарстан, Высокогорский муниципальный район, Высокогорское сельское поселение, с. Пановка, выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границ и(или) площади земельного участка. Заказчиком кадастровых работ является Ибениев Рамиль Рустамович (Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 43а, кв. 37), тел.: 89196999313. С проектом межевого плана можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: 420107, РТ, г. Казань, ул. Марселя Салимжанова, д. 14, пом. 1, тел.: 89178883476. Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: Республика Татарстан, муниципальный район Высокогорский, сельское поселение Высокогорское, село Пановка, улица Молодежная, земельный участок 55 01.09.2022 г. в 09 часов 00 минут. Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы: 16:16:190101:268, 16:16:190101:319, 16:16:190101:812. При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок. Обоснованные возражения и предложения по доработке проекта межевого плана относительно границ, содержащихся в проекте межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются в письменном виде с даты опубликования данного извещения по 01.09.2022 г. по адресу: 420107, РТ, г. Казань, ул. Марселя Салимжанова, д. 14, пом. 1.

Илдар Мөхәммәтҗанов (фотоиллюстрация өчен бирелә)

«Өмет»сезләр

Шәхсән үземә атап язылган бу хат шактый ук аптырашта калдырды мине. Аны Арча районы Яңа Кенәр авылы ветераннары язган. «Бездә «Өмет» социаль тернәкләндерү үзәге бар иде, 2008 елдан бирле эшләп килде. Узган ел ялган сәбәпләр табып, шуны яптылар. Якташыбыз – «Безнең гәҗит»не нәшер итүче Илфат Фәйзрахманов, ТНВдан Данил Гыйниятов, «Акчарлак» газетасыннан Габделфәт Сафин, «Татар-информ»ның баш мөхәррире Рәмис Латыйпов «Өмет» ябылу турында үз фикерләрен белдерделәр. Хөрмәтле якташыбыз, сез дә бу хакта «әйтеп кенә баксагыз» иде», – дип миңа да төрттерел куйганнар. «Өмет»сез калганнар Президенттан башлап, прокуратурага, хөкүмәткә, Дәүләт Советына, министрлыкларга, кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә дә мөрәҗәгать иткәннәр, әмма уңай җавап алмаганнар...

Бөтен җавапларны җыеп барганнар. Авыл җирлеге башлыгы Әгъзам Гайфуллин аларны миңа биреп җибәрде: «Рәхәтләнеп укы әле», – диде. Бер дә рәхәт түгел иде аларны уку. Җаваплар, нигездә, бер үк эчтәлектә, хәтта бер үк җөмләләр кабатлана. Яңа Кенәр ветераннары моны «отписка» дип кабул иткән. Шәхсән үземдә дә шундыйрак тәэсир калды.

«Өмет»не бетерүнең сәбәпләре нинди соң? Беренчедән, үзәк урнашкан бинага капиталь ремонт кирәк икән. Ә ул хастаханә бинасының бер канатында урнашкан. Әгәр бина авария хәлендә һәм аңа кеше керергә ярамый икән, нигә хастаханә эшли, ә «Өмет» ябыла? Бинаның хастаханә өлеше күпкә начаррак та әле.

Икенчедән, канализацияне ремонтлау кирәк, дигәннәр. Ә җирлек башлыгы әйтүенчә, канализация 2014 елда ремонтланган, ТКХ оешмасы аны гел чистартып тора, бернинди ис тә юк, торбалардан килгән су чиста.

Инде килеп, бина янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килми икән. Әйтүләренчә, сигнализация эшли, янгын сүндерү җайланмалары, эвакуация планы бар, чыгу юллары ачык, җаваплы кешеләр куелган. Янгын сүндерү бүлеге бина белән янәшә генә диярлек, бүлек башлыгы Хәниф Әхмәтов актның янгынга кагылышлы җирен укыгач аптыраган һәм көлеп куйган, ди. Үзенә дә шалтыратып алдым: «Ул бинада барысы да тәртиптә, бернинди кимчелек юк», – диде.

Актта әле бинаның террорчылыкка каршы тору таләпләренә туры килмәве дә язылган. Үзем булдым мин анда. Керә торган ишекләр тимердән, нык. Төп ишектә «глазок», видеокамера бар. Туганнары, дуслары белән очрашырга килүчеләрнең исемен журналга язып, кул куйдырып, директор рөхсәте белән генә кертелүен дә әйттеләр. Паспортларын вахтерда калдырып торалар икән.

Тикшерүчеләр бинаның санитария-эпидемиология таләпләренә «туры килмәвен» дә ачыклаганнар. Ул таләпләрне мин белеп бетермим инде, әмма җирле җитәкчелек, «Өмет»тәге чисталыкны, матурлыкны санап бетерерлек түгел иде, ди. «Өмет» тернәкләндерү үзәге – хастаханә түгел, анда дәвалану өчен килмиләр. Әлбәттә, анда массаж ясаганнар, парафин, электрофорез, магнит терапиясе, ингаляция булган. Әмма иң беренче чиратта үзәккә кеше, исеменнән аңлашылганча, социаль тернәкләнү өчен килгән. Психологик яктан савыгу алганнар алар. «Алар» дигәнебез, тыл ветераннары, үзләре язуынча, «чабата киеп, батa-чума черек бәрәңге җыеп, хәерчелектә, ялангачлыкта үскән сугыш чоры балалары». Тернәкләндерү үзәге алар өчен – шифаханә.

Берәү хәтта: «Сугыш чоры балаларының үлеп беткәнен дә көтмәделәр, ичмасам», – дип куйган иде. Исемен язмаска кушты. «Өмет»нең кинәт яраксыз дип табылуына бик сәерсенә Яңа Кенәр кешеләре. Бүген Яңа Кенәр авыл җирлегендә дүрт меңнән артык кеше яши, шуның яртысы чамасы Яңа Кенәрнең үзендә. «Өмет»кә күрше-тирә районнардан да бик теләп килгәннәр, елына 700ләп кеше ял иткән. Аз керемлеләр, аз пенсия алучылар, бер тиен түләмичә, тәннәренә-җаннарына шифа алганнар. Кул эшләре белән шөгыльләнгәннәр, бергә җырлашып утырганнар, китаплар укыганнар. Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы исә «социаль тернәкләндерү үзәген бетерү районда яшәүче өлкәннәр һәм гариплегә булган затлар өчен социаль ышанычларның кимүенә китермәде» дип саный. Һәрхәлдә, министрлыкның бер җавабында шундый сүзләр язылган. Шуның өстенә министрлык, китап уку, күңел ачу өчен, район үзәгендә китапханә, мәдәният йорты бар һәм шул җиткән дип саный. Ә авыл халкы: «Без – 80–90 яшьлекләрнең 40 чакрым үтеп, уйнарга бару чорларыбыз үткән. Безгә йорт-җирләребездән ерак булмаган дәвалану урыны кирәк», – ди.

Арча муниципаль районы башлыгы Илшат Нуриев әйтүенчә, «Өмет» социаль тернәкләндерү үзәгенең ябылачагы турында хәбәр чыккач та, ул республика җитәкчелегенә хат юллаган. Тик уңай җавап алмаган. Уйлавымча, министрлык Президентны «Өмет»нең юкка чыгуы халыкка зыян китермәсенә ышандырган. Дөресен әйткәндә, бу мәсьәлә белән Рөстәм Миңнеханов шөгыльләнергә дә тиеш түгел, аның мәшәкатьләре болай да хәттин ашкан. Сүз уңаеннан, авыл халкы үзе дә аңа олы хөрмәт белән карый, мондый хисләрен бихисап мөрәҗәгатьләрдә дә белдергән. Монда гаеп «тәртә»дәдер дип уйлыйбыз. Халыкны социаль яклау өчен системалы эш алып барылуы турында матур итеп сөйләргә яратучылар мәсьәләнең алдын-артын уйлап бетермәгәннәрдер кебек тоела.

Без авылларны яшәтү, район-авыл җирләрендә социаль инфраструктуралар булдыру турында сөйлибез, шул ук вакытта булганны юкка чыгарырга да күп сорамыйбыз. Шунысы кызык һәм кызганыч: «Өмет» үзәген бик тиз арада япканнар һәм андагы барлык җиһазларны тиз-тиз генә каядыр ташып та бетергәннәр.

Кайбер мәгълүматларны ачыклау өчен, Арча социаль яклау бүлеге җитәкчесе Миләүшә Шакировага шалтыраткан идем. «ВТ» журналисты икәнемне белгәч: «Все вопросы пресс-центру министерства», – дип кенә куйды. Минем урысчам анык дәрәҗәсендә түгел инде, бары тик: «Так и запишем...» – дип әйтү белән чикләндем. Ә бит массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы законда безнең теләсә нинди мәгълүматны алырга хокукыбыз барлыгы язылган. Әлбәттә, «дәүләт сере булмаса» дигәнрәк искәрмә бар. Күрәсең, министрлык һәм аның район бүлекләре эше «дәүләт сере» исәпләнә дигән уй туган иде. Аннан: «Ялгышсам гына ярар иде», – дип күңелне тынычландырдым үзе. Дөресен әйткәндә, шәхсән Миләүшә Шакировага бернинди дәгъва белдерә алмыйм. Без һәрберебез – система җимешләре һәм вакыты-вакыты белән авызны үлчәп ачарга тиешбез.

Дәүсовет Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның бер сүзе бик ошый миңа. «Без халыкка һәрвакыт ачык», – дияргә ярата ул. Әмма хакимиятнең кайбер тармаклары бик ачылып бетәргә, халык белән аңлашып эшләргә яратмыйлар. Арчаның хөрмәткә лаек ветераннарын «Өмет»сез калдырырга ниятләгәндә, мәсәлән, нигә бераз халык фикеренә колак салмаганнар икән? Белүемчә, Яңа Кенәргә дә министр үзе түгел, ә аның урынбасарлары гына килгән. Аннан соң Россия Дәүләт Думасына депутат итеп Арчадан сайланган Илдар Гыйльметдинов бу хәлгә ни өчен битараф калган икән? Халык аңа да мөрәҗәгать язган, тик бернинди дә җавап килмәгән. Шуларны уйлыйм да, астагылар үзенчә, өстәгеләр үзенчә яшидер кебек тоелып китә.

Яңа Кенәрдәге «Өмет» инде яңадан ачылмас. Халык аптырашта, заманында әллә ничә предприятиесе булып, гөрләп яшәгән авылның гомере һаман да санаулы була баруыннан курка ул. Тора-бара хастаханәне дә ябмаслар микән дип шикләнә. Чөнки анда уртак бер котельный булып, кышларын «Өмет» ягы да җылыта, ә үзәк инде юк. Җылылык өчен бушка акча әрәм итәселәре килмәс дип әйтүем. Хастаханәне башта көндезге стационар иттеләр, ә аннан... Күңелсез уйларны куасы килә, әмма шикләнү кала бирә.

Хәзергә өлкәннәрнең, гомумән, сәламәтлеге какшаганнарның кечкенә генә бер юанычлары бар: хастаханәдә таныглан табиб Әнвәр Вафин атнага бер тапкыр халыкны кабул итә башлаган. Ул күрше Ташкичү авылы егете, алтын куллы хирург. Аны Яңа Кенәргә килергә кодалаган өчен җирле җитәкчегә һәм район башлыгына рәхмәт. Миңа хастаханәдә Әнвәр Вафинның кабул итү көне туры килде. Колак чите белән тыңлап тордым: халык табибка да, җитәкчеләргә дә бик рәхмәтле иде.

Менә шул, хат язучылар үтенгәнчә, Яңа Кенәр вакыйгасына карата үз сүземне «әйтеп кенә бактым». Шул ук вакытта, киләчәктә сүзнең дәвамы булмагае, дип тә уйлап торам. Чөнки ул ярдәмгә мохтаҗ буынга, авыл язмышына кагыла.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Тернәкләндерү үзәгенең язмышын Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан тагын бер мәртәбә белешәсе иттек. Министрлыкның матбугат үзәгендә әйтүләренчә, әлеге учреждение 1,5 ел элек ябылган, сәбәпләрен дә халыкка аңлатканнар. Кыскасы, өстәп әйтер сүзләре юк.

ЯЛ ИТКӘНДӘ ЭШ ТУРЫНДА


Илдар Мөхәммәтҗанов

Безнең тирәдә яшәүчеләр көтү каршылауны, шаяртып, русчалап, «совещание» дип йөртәбез. Соңга кала күрмә, әйдә, чык инде, дип чакырышабыз да, кичә юк идең, шелтә эләгә бит, дип кисәтешәбез. Көтү кайтырга ун-унбиш минут алдарак кына чыксак та, шул вакыт дөнья, авыл хәлләрен сөйләшергә дә, эш күп, дип зарланышырга да вакыт җитә. Бүген кайсыгыз нәрсә эшләде, дип башлыйбыз да...

Белмим, башка елны да шулай булдымы икән, быел эш бигрәк күп, бөтенесе бергә бөялде дип, әле һаман да соңга калып килгән яз белән җәйне гаепләп алабыз. Анысы чыннан да шулай: җәй башымы бу, җәй ахырымы – һич аңлый торган түгел. Кемдер әле һаман да җиләккә йөри, кемдер үз бакчасыннан карлыган, кура җиләге, кара бөрлегән җыя, өлгеррәкләр инде чиядән компот та ябкан. Кыяр-помидор тозлаучылар да бар, кемнекеләрдер әле яңа өлгерә, кемдер инде сарымсакларын, көздән утырткан суганнарын йолкыган. Яз көне утырткан суганнар да тамырны әйбәт җибәргән инде анысы. Кыяклары ямь-яшел булса да, йолкыйсы булыр... Әйдә, кыякларын турап, туңдыргычка куярбыз, кышка витамин булыр... Кыскасы, җиләк вакытымы бу, печән өстеме, көзге эшләр башланамы – һич аңламассың (сарымсак-суган йолку көзге уңышны җыя башлау бит инде). Эшнең дә кайсын эшләргә, кайсын чиратка куярга белеп булмый.

Ни арада өлгергәннәр диген, көннәр коры торганда дип, бөтен авыл дәррәү икенче кат печәннәрен чаптырган, эссе, коры торган көннәрдә җыйнап та алган булып чыкты. Монысын да шул «совещание»га чыккач белдем. Берәр генә көнгә соңга калганнарыкы да яңгырга эләкте. Хәер, печән чапкач, авылда яңгыр яву гадәти хәл инде ул. Район үзәгендә бер тамчысы таммаса да, әнә шушы көннәрдә генә дә безнең кипкән печәннәргә чиләкләп койды.

Шулай да бу көннәрдә көтү каршылаганда сүз күбесенчә бәрәңге турында.

– Безнең бәрәңгегә фитофтора төште инде, бер өлеше саргайды, казып, үзебез дә ашыйбыз, малларга да ашата башладык... Ничә тапкыр дару сипкән булдык... Бәрәңгесе әйбәт үзе...

– Ярый әле сез иртәрәк утырткан идегез, безнекеләргә 60 көн тирәсе генә. Фитофтора төшсә, үсә дә алмый калалар бит...

– Ничә ел инде агу сибәсе булмасын дип, бәрәңгене утыртканда ук агулап утырта идек. Бер елны да колорадо корты чыкканы булмады. Быел да юктыр, дип бакчага төшеп тә карамадык. Чүбен утыйк, дип төшсәк, дүрт буразнадагы бәрәңге яфрагын ашап бетерә язганнар.

– Быел бәрәңге сабагы гайрәтле булып үсеп киткәч, бакчада чүп юк, чиста, дип йөри идек, карасак, эт эчәгесе баскан. Ярый әле бәрәңгегә чорналып өлгермәгән... Бу вакытта чүп утау бер дә җайлы түгел икән: ни чүгәләп утап булмый, ни арасында йөреп булмый, эт эчәгесен тамырыннан ычкындырып кына калдырдык. Башка елны бу вакытта өскә чыккан чүпләрне генә җыя идек бит... Яшелчә бакчаларын да ничә кат утасаң да, чүбе бетә торган түгел...

Гайбәткә урын да, вакыт та калмый күрешкән арада. Ни дисәң дә, «совещание» бит! Дөрес, эш күп, дип тә зарланган кыяфәт кенә чыгарабыз. Беребез дә шушы авылдан китеп, башка урында, бигрәк тә шәһәрдә яши ала торган кеше түгел, ул турыда хыялланмыйбыз да.

Шәһәр димәктән, бер көнне танышым сөйләп көлдерә. «Улым беренче мәртәбә отпускысы чыкты бит (башта укыды, аннан армиягә барып кайтты, укыган елларында ук эшләде, каникулда авылда тормады). Әйттем, берәр кая ял итәргә бар, дип. «Әни, сигез ел инде авыл җәе күргәнем юк, иң рәхәт ял – авылда», – дип, өйгә кайтты бу. Сөенә-сөенә эшләрне әзерләп кенә тордык. Үзе дә иртүк тора, бөтен авыр эшләрне: «Менә бу ичмаса фитнес», – дип, бер авырсынмый эшли. Абзарларны, каралты-кураларны да тәртипләп чыкты, бәрәңгеләрне дә агулады, басудагы печәнне, бер нәрсәсе юк дип, бензинлы чалгы белән генә чапты. Тик җыярга кигәвен котырган, бик тә эссе көннәр туры килде. «Әле ярый компьютерга укыганмын, эшем бик әйбәт икән минем», – ди балакаем, баш миләрен көйдерерлек эсседә эшләп алҗыгач. Авылны макта, шәһәрдә тор, дип белеп әйткәннәр шул инде аны, улым, дим. Тик безгә сезнең ул мактаулы шәһәрегез кирәк түгел, дидем.

Кем кайда иялләнгән шул инде. Әнә күрше Пүскән авылы әбиләре Болгарга экскурсиягә барган булган. Бөтенесен ошатканнар, әмма зур су күреп, курка калганнар. Безнең якларда андый сулар юк бит, үзебезнең инешкә җитми, дип кайтканнар. Безгә дә әнә шул «совещание»ле үз авылыбыз якын, дөньяның иң матур җире шул лабаса.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ТӘМЛЕ ГЕКТАРЛАР

Автор фотосы

Әгерҗе районының бер урамлы кечкенә генә Касай авылында гомер кичерә Әминә һәм Альберт Әхмәдиевләр. Уллары Айнур белән Искәндәр Казанда югары уку йортларын тәмамлаганнар, сәүдә өлкәсендә хезмәт куялар. Башкалага китеп төпләнсәләр дә, туган авылларын чиксез яраткан егетләр моңа кадәр дә ара ерак дип тормаган, әти-әниләре янына еш кайтып йөргән. Ә җиләк араны тагын да якынайткан.

Бер сүз җитә

– Бер кайтканда, улларыма теплица куеп, бакча җиләге үстереп карау теләгем барлыгын әйттем, – ди Әминә апа.

Озак та узмый, Айнурга эшчәнлегенә бәйле конференциядә катнашырга туры килә. Анда җиләк үстереп, зур табыш алу мөмкинлеге турында сөйлиләр. 2017 ел була бу. Шуннан соң егетләр өчен Касай белән Казан арасындагы 350 чакрым юл тагын да кыскара. Җәй чыгуга, туган авылларына ашкына алар. Җиләк үстерү технологиясен өйрәнәләр, туфракны тикшертәләр, безнең як климатына туры килердәй сортлар эзлиләр...

Сигез сутыйдан башланган эш

Өй янындагы сигез сутый бакчадан башлана эш. Голландиядән җиләк сортлары кайтып җиткәнче, озын түтәлләр ясап, аның асларына сугару җайланмасы урнаштыралар, ягъни суны торбалар аша китертеп, тамчылап сибелә торган итеп ясыйлар. Ул елны сигез сутыйга өч мең төп җиләк үсентесе утырта Әхмәдиевләр.

Шул елны ук 400 килога якын уңыш җыялар. Бу егетләрне канатландырып җибәрә. Икенче елны мәйданны тагын шуның кадәргә арттыралар. «Хоней», «Еви 2» сортлары безнең як климаты өчен бик кулай булып чыга. Җиләк үрчетүгә киткән чыгымнар да каплана, файдасы да кала.

Ике ел рәттән аз гына мәйданнан күпләп уңыш алган егетләр моның белән генә тукталып калмаска уйлыйлар. Дөрес, матди яктан кыенлыклар була, әмма аларга инвестор ярдәмгә килә. Күп тә үтми, авыл янәшәсендәге кырга 230 метрлы биш теплица куела.

– Эш башлаганда күп нәрсәне аңлап та, белеп тә бетермисең. Без дә теплицада үскән җиләктән күбрәк уңыш алырбыз дип хыялландык. Чыгым, әлбәттә, күп тотылды. Әмма теплицаларыбыз көчле җилгә каршы тора алмады һәм бу алым турында онытырга туры килде, – дип сөйли Айнур.

Ярый әле, 2018, 2019 елларда эш башлаучы фермерлар өчен тәгаенләнгән федераль грантта катнашып, өч миллион сум акча оталар. Нәкъ менә шул елларда Әхмәдиевләрнең җиләк мәйданы өч гектарга җитә.

Кышны чыга алмадылар

Авырлыклар моның белән генә бетми. 2019 елның салкын кышында бер гектар мәйданда җиләк үсентеләре өши.

– Бу да зур сабак булды безгә, – ди хуҗабикә Әминә апа. – Аңа кадәр көз көне җиләкләрнең яфрак-сабакларын кисә идек. Бер авыз пешкәч, өреп кабасың икән, шуннан соң кискәнебез булмады. Хәзер кышка кергәндә салам белән дә каплыйбыз.

Шулкадәр мәйданда җиләк үсентеләрен югалткач, кемдер, бәлки, бу шөгыльгә кул селтәгән булыр иде. Әмма Айнур да, Искәндәр дә артка чигенергә уйламыйлар.

– Бу авырлыклар безне җиде кат үлчәгәннән соң гына кисәргә өйрәтте, – ди Айнур.

Рекордлы ел

Хәзер Әхмәдиевләр ике гектар мәйданда бакча җиләге үстерә. Быел уңыш сөендерерлек булган.

– Рекорд куйдык, – ди Айнур. – Алты тонна җиләк җыйдык. Мондый уңыш биш елга беренче тапкыр булды. Җиләкләр дә бик эре, сусыл, баллы. Бер атна эчендә узган елгы уңыш күләмен җыйдык. Әле тагын булачак. «Еви 2» – ике тапкыр җиләк бирә торган сорт. Янә чәчәк ата башлады. Көзен һава торышы әйбәт торса, бу сорттан гына яңадан ике тонналап җиләк җыярга өметләнәбез. Җиләк, үсентеләр сату буенча бернинди проблема да юк. Бу эш күптән җайга салынды инде. Җиләкләр Сарапул, Ижау, Чаллыга да китә, райондашлар да яратып ала.

Буа да буганнар, ашлык та үстерәләр

Җиләкләргә су сибү өчен, Әхмәдиевләр берничә ел элек авыл белән янәшә генә буа буганнар. Анда карп балыклары да үрчетәләр. Арендага җир алып, Альберт абый солы, арпа чәчкән. Көзен арыш та чәчәргә уйлыйлар. Киләчәктә җиләк мәйданын тагын да арттыру теләкләре бар икән. Иң мөһиме, егетләр туган авылларын яраталар.

– Утыз гына хуҗалык булса да, Касай башка авыллардан ким яшәми. Күп мал асраучы, бакча үстерүче, бал кортлары тотучы хуҗалыклар бар. Йортлар төзек, матур, кешеләр дус, тату, табигате искиткеч. Шуңадыр, авыл, туган нигез, әти-әни һәм күп көч, хезмәт куйган җиләк кырларыбыз да үзенә тарта... – ди Айнур.

Миләүшә ЯГЪФӘРОВА

ИКЕ БАЛАСЫН ЮГАЛТКАН АНА:

«ЙӨРӘК ЯРАСЫ ГОМЕРЛЕККӘ КАЛА ИКӘН»

Лаеш районының Кабан авылында яшәүче Диләрә Гыйлемханова җиде ай инде күз яшьләрен коя.

Узган елның 31 декабрендә Түбән Камага Яңа ел бәйрәмен каршыларга киткән улы гаиләсе белән фаҗигагә очрый. Килене Ләйсән шунда ук үлә. Улы исә операцияне күтәрә алмый. Ике оныгы да авыр хәлдә була. Табиблар аларның гомерен саклап кала. Оныклар хәзер әби белән бабай тәрбиясендә үсә.

– Киленем Ләйсәннең бик тә безне Казанга күчендерәсе килде. Без Түбән Камада яши идек. «Әни, әйдә яныбызга килегез», – дип кенә торды. 2019 елда без Лаеш районына күчендек. Ул чакта балаларның сөенгәннәрен күрсәгез! Ирем Әсгать белән ике ул үстердек. Олысы Илнур да, кечесе Илшат та Казанда яшәде. Шуңа да безне китерәселәре килгәндер дип уйладык, – дип сөйли Диләрә апа. – Хәзер менә бу фаҗигадән соң аңладым инде – киленемнең балаларын ялгыз калдырасы килмәгәндер, мөгаен.

Түбән Камадан күченгәч, алар бер ел бернинди борчу-хәсрәтсез, бик бәхетле яшиләр. 2021 елда Диләрә апа авырып китә. Аның телендә яман чир табалар. Җитмәсә, авыру тарала. Күзенә күчә, лимфа төеннәре зурая. Диләрә апага декабрьнең алтысында операция ясыйлар. Ул вакытта килене Ләйсән янында да

Диләрә Гыйлемханованың шәхси архивыннан

китми. Табиблар, палатага кертмибез, дисәләр дә, җаен таба. Качып булса да, әнисе янына кереп, аңа ярдәм итә. Үзенең әти-әнисен бик иртә югалта Ләйсән.

– Без тумышыбыз белән Балык Бистәсе районының Татар Казаклары авылыннан. Кодагыйларыбыз күрше генә иде, – ди Диләрә апа. – Ләйсән белән Илнур 22 яшьтә үк өйләнеште. Тормышны яратып, бер-берсенең кадерен белеп яшәделәр. Мин киленемнең үзебезгә булган мөнәсәбәтенә шакката идем. Үзем дә, килен булып килгәч, бернинди авыр сүз әйтмәдем, аннан кимчелек эзләмәдем. Ул исә Илнурга да әйбәт булды, безне дә хөрмәт итеп торды. Столбищедан йорт сатып алдык. Ләйсән кызларын ияртеп килеп керә дә, әти-әни, барыгыз, урамда йөрегез, дип безне ял иттерә, үзе ялт итеп өйне җыештырып чыгара иде. Шул арада коймагы да пешкән булыр иде. Безне чиста өйдә чәй табыны янында көтәр иде. Бик сагынам үзләрен. Еламаган бер көнем юк.

...Фаҗига буласы көнне Илнур белән Ләйсән башта әти-әнисен бәйрәм белән котлап, Түбән Камага Ләйсәннең бердәнбер сеңлесе Айгөл гаиләсенә юл тоталар. Күп тә үтми, Диләрә апаның телефонына шалтыраталар да: «Илнур Гыйлемханов сезнең улыгызмы?» – диләр. Аларның юл фаҗигасенә очрауларын, Ләйсәннең үлүе турында җиткерәләр. Ата белән ана бөтенләй коелып төшә. Бер генә теләк – калганнар исән-сау булсын! Ярты юлны узгач, Илнурның да үлгәнен әйтәләр.

– Барып җиткәнебезне хәтерләмим. Ничек исән калганбыздыр. Хәлебез чиктен иде. Мондый ачы хәсрәтне дошманының да күрсәтмәсен! Йөрәк ярасы гомерлеккә кала икән. Кешеләр, сабыр итегез, вакыт дәвалый, диләр. Ничекләр түзәргә соң? Әле ярый ике оныгым исән калды. Алар яшәргә көч бирә, – ди Диләрә апа.

Әдиләнең башына, Ясминәнең кулаякларына зыян килә. Берсенә – 11, икенчесенә 17 яшь аларның. Әдиләне табиблар комага махсус җибәрә. Ясминәгә исә бик катлаулы операцияләр ясыйлар. Ул чакта кызларны Айгөл апалары карый. «Әниебез кайда?» – дигән сорауга да аңа җавап бирергә туры килә.

– Башта Айгөлебез балаларга опекун булып торды. Хастаханәдән чыгуга без аларга күчендек. Әдилә кызым техникумда укуын дәвам итә алды. Ясминәнең аякларында аппарат булгач, ул май аена кадәр өйдә булды. Укытучылар килеп укытты. Аллага шөкер, акрынлап уңайлана инде, – дип сөйли Диләрә апа. – Гел борчылып торгач, минем сәламәтлегем какшады. Чирем кузгалды. Яңадан дәваланырга кирәк. Соңгы анализларым яхшы иде. Тик менә шешенүем бар. Ничек тә чирләремне онытасы иде. Безнең бит оныкларны аякка бастырасыбыз бар. Ул балаларны икенче кат ятим итмәскә иде. Алар безнең өчен нишләргә дә белми. Еласам, юатырга гына торалар.

Диләрә апа «Ватаным Татарстан»ны даими укып бара икән. Ул безгә үзе шалтыратып, язмышын сөйләде. Сүзен тәмамлап, болай дип тә өстәде:

– Минем язмышым башкаларга гыйбрәт булсын. Матур итеп яшәргә тырышыгыз. Кемнең кайчан китәсен берәү дә белми. Хәзер уйлыйм да сөенеп куям – ярый әле киленемне баламдай күрдем. Өч көнлек дөнья бит бу! Улларыгыз сайлаган чит кеше баласын яратыгыз! Берәүгә дә бала хәсрәтләре кичерергә язмасын. Илнурым төшемә бер керде. Ак күлмәген киеп, кырыйдан гына карап тора иде. Ләйсәнем туганнарыма кергән. Җиләк җыйган икән. Ризадыр бәгырь кисәкләрем!

ЙОРТ УРЫНЫ – КАРА КҮМЕР

Питрәч районының Шәле авылында яшәүче Рәдиф Гыймадиев хуҗалыгында ут чыгып, йорты, каралты-курасы, тавык-чебешләре, хәтта ишегалдындагы машинасына кадәр янып бетә. Дүрт кызын берүзе тәрбияләүче иргә ярдәм кирәклеге хакында хәбәр социаль челтәрләрдә тиз таралды. «ВТ» журналисты Рәдифнең үзенә шалтыратты. Аның язмышы да күпләргә гыйбрәтле.

– Гомерем буе фермер булып эшләдем. Безнең гаиләне күпләр белә иде. Булачак хатыным белән күршеләр генә булып яшәдек. Өйләнешкәндә аңа – 21, миңа 23 яшь иде. Икебез дә дингә килдек. Дүрт кызыбыз туды. Матур гына тормыш иттек. Үз хезмәтебез белән яшәдек. Әмма бер ел элек кинәттән генә хатыным балаларны алып юкка чыкты, – дип сөйли Рәдиф. – Ул чакта үзем басуда идем. Өйгә кайтсам, бер кеше юк. Аннары гына аларны нинди машина кайтып алганын белдем. Берничә ай ялгыз яшәдем. Бераздан кызларым шалтыратып, әти, безне моннан килеп ал, диделәр. Мин барып җитәргә өлгермәдем, алар үзләре кайтты. Өйгә керделәр дә, башка чыкмадылар. Әниләре үзләре генә китте. Ә мин исә хатынымны яратып яшәдем. Кире әйләнеп кайтыр дип көттем.

Рәдиф, ул чакларны искә алганда да, күңел тула, ди. Әмма кызларының, әтием, дип өзелеп торуы яшәргә көч бирә икән үзенә. Олы кызы Энҗегә – 20 яшь, ул Казанда педагогика көллиятендә укый. Язгөлгә – 15, Диләрәгә – 14, Әдиләгә – 10 яшь.

– Балаларым мине бик ярата. Аеруча кечесе. Иртән чыгып киткәндә, 75 тапкыр үбә. Юри санадым. Ничекләр шул балаларны яратмыйсың инде?! Шөкер, акыллы булып үсәләр. Дүртесе дә биш вакыт намаз укый. Өйдәге бар эшне эшлиләр. Олы кызларым ашарга да пешереп куя. Язгөл татар теленнән республика олимпиадасында җиңде. Бик тырышып укыйлар. Шуларга карап, бар борчуым онытыла, – ди ул.

Өйдә янгын чыккан көнне алар Лаешка кунакка барган. Диләрәнең өйдә каласы килгән, йоклаган. Алай да аны уятып

Энҗе Гыймадиеваның шәхси архивыннан

алып киткәннәр. Хәзер Рәдиф шуңа сөенеп туя алмый. Йортка ут кабу сәбәбен әле ачыкламаганнар иде. Шушы көннәрдә хатыны белән милек бүлешү буенча суд утырышы планлаштырылган. Йорттан берни калмаган, ә уртак җирләре бар.

Хәзер Рәдиф дүрт кызы белән аның әти-әнисендә яшиләр. Өйләре зур булмаса да, сыйганнар инде. Әтисе, авырып, урын өстендә ята икән.

– Алга таба йорт та салыр идем. Тик мин җирләрне хатыным һәм аның әнисенә рәсмиләштердем. Болай булырын кем белсен? Хәзер ул җирләргә өметләнмим дә. Хәтта юрист та яллмадым. Аллаһы Тәгалә нәрсә язган, шул булыр, дип сабыр итәм. Безнең гаиләгә ярдәм итәргә теләүчеләргә рәхмәтле булыр идем, – ди Рәдиф.

Гыймадиевлар гаиләсенә булышырга теләүчеләр өчен олы кызы Энҗенең 89393883372 телефон номеры Саклык банкы картасына беркетелгән.

Игълан тактасы

КЕМГӘ КИРӘК?

▸ 13–14 яшьлек кыз бала өчен җәйге киемнәр бар.

Елена. Казан

* * *

▸ Яхшы хәлдәге, берничә тапкыр гына киелгән 48–50 үлчәмдәге кышкы тун, 39 үлчәмдәге көзге, кышкы аяк киеме бирәм.

Ләйсән. Лаеш

* * *

▸ 42–44 үлчәмле хатын-кыз киемнәре бирәм. Бер дә киелмәгән җәйге күлмәк, кофта-чалбарлар бар.

Роза. Казан

КЕМДӘ БАР?

▸ 7 яшьлек кызга, 10 яшьлек малайга киемнәр бирүче булмасмы?

Фәния. Казан

* * *

▸ Берәр кешедә 46–48 үлчәмдәге хатын-кыз, 14 яшьлек кыз балага яраклы киемнәр булмасмы икән?

Айсылу. Казан

* * *

▸ 12 яшьлек ир бала өчен киемнәр кирәк иде. Бирүче булса, редакциягә хәбәр итүен сорыйм. Үзем килеп алыр идем.

Гөлия. Казан

▸ 16 яшьлек кызым өчен 44–46 үлчәмле киемнәр бирүче булмас микән?

Гөлшат Шакирова. Питрәч

Элемтәгә керү өчен телефон: 222-09-67.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ЛӘЙСӘН МӘХМҮТОВА:

«ИҢ ЯРАТМАГАН НӘРСӘ – ИДЕЯ ӨЧЕН АКЧА ЭЗЛӘҮ»

Ул булган җирдә тормыш кайный. Һәрхәлдә Татарстанның атказанган артисты Ләйсән МӘХМҮТОВА янында тыныч калып булмый. Шунда ук идеясе туа, шунда ук сине кызыксындыра, үзе артыннан ияртә. Без аның белән мәдәни тәҗрибәләр, аларның файдасы һәм зыяны, кино сәнгате турында сөйләштек.

:: Ләйсән, театр һәм «Зә-Ләй-Лә»дән соң сине популяр иткән өлкә – кино. «Уеннан уймак» сериалын, мәсәлән, ике сезон түгел, 3, 4 сезон итәргә була иде. Кино режиссеры буларак тагын идеяләр юкмы?

– «Уеннан уймак»ны берничә сезонлы итеп була иде, әлбәттә. Хәл ителмичә сузыла килгән берничә сәбәп аркасында тукталып калды ул. Башта ничек дәвам иттерергә икәнен белми идем, аннары инде, ниһаять, фантазия эшли башлаганнан соң, акча табу мәсьәләсе килеп басты. Аннары әни авырып китте, пандемия килеп чыкты... Сценарийның төп идеясе үзгәрә башлагач, тагын туктап калды. Хәзергә илһам килгәнне көтәбез һәм вакыйгалар агышын күзәтәбез.

Карагыз әле, мине, зинһар, кино режиссеры дип язмагыз. Бу – бик бөек исем, мин – шул тирәдә буталып йөри торган хыялый кеше генә. Яңа идеяләр бар, әлбәттә, шуларны җиң сызганып, җиренә җиткерергә кирәк. Бер әзер сценарий да бар, анысы үз сәгатен көтә. Иң яратмаган нәрсә – идеяләрне тормышка ашыру өчен акча эзләү. Менә моны укып, берәрсе алып килеп бирмәс микән, мәгез, берәр күңелле әйбер төшерегез әле диеп *(көлә)*.

:: Бездә кино бар дип әйтеп була инде, ләкин бит бөтен халык та күреп өлгерми аларны. Шул ук «Эпипә». Әйтерсең авыл халкы, кинозалга барып, кино карый. Көн-төн татар киноларын күрсәтә торган канал кирәкме икән әллә безгә?

– Мин дә шулай дим! Көн-төн татар фильмнарын, сериалларын күрсәтә торган канал булырга тиеш ул, һичшиксез! Ә нишләп булмасын ди әле?! Мин үзем дә – кызганыч, күпме татар фильмнарын күрмәгән кеше, рәхәтләнеп карар идем. Яхшысын да күрсәтсеннәр, чиле-пешлесен дә. Ошамый икән, башка каналга күчәсең генә, проблема түгел бит. Урысларда шулай, бездә дә сайлап алырга мөмкинлек булсын.

:: Якутларда кино бар, диләр. Синеңчә, кечкенә генә милләт сәнгатьтә ничек шулай алдырып китә алган? Без күбрәк тә, ләкин алай мактана алмыйбыз бит әле.

– Якутларда, бәлки, кинога караш җитдирәктер, ә бәлки кино төшерә торган шәхесләре көчлерәктер. Алай дисәң, бездә дә талантлы режиссерлар да, гомумән, универсаль төшерү төркемнәре дә, артистлар да бар. Минемчә, дәүләт карамагында булырга тиеш бу өлкә. Дәүләте кирәксенгәнгә, аларда кино үсеш алгандыр.

:: Сәнгать дигәннән. Экспериментларга ничек карыйсың? Менә Тинчурин театры «Умай» лабораториясе җимешен күрсәтте. Кабул иттеңме ул операны?

– «Умай» турында... Мин тәнкыйтьче түгел, үз фикеремне генә әйтәм. Гәрчә үземне замана кешесе һәм модный әйберләрне аңларлык дәрәҗәдә дип санасам да, миңа бу постановка ошамады. «Ошамады» дигән сүз йомшак әйтелгән әле монда.

> **Блиц-сораштыру**
>
> **– Яраткан ризыгың?**
> – Итле ризыклар.
> **– Тормышың кино булса, ул ничек аталыр иде?**
> – «Башыңны эшләт, дөнья бу!» дигән исем бирер идем.
> **– Кешедә иң яратмаган сыйфат нинди?**
> – Алдашу.
> **– Иң яхшы сыйфат кайсы?**
> – Тулаем алганда, әйбәт кеше булу.
> **– Соңгы укыган китап?**
> – Китап... Ммм, эзләп карап әйтермен.

Кайчандыр Камал театрында «Тормышмы бу?» дигән искиткеч спектакль карадым. Аның режиссеры Айдар Җаббаровка – нибары 26 гына яшь, ә нинди иҗат! Шаккатып, тетрәнеп кайттым. Үземне Мәскәү театрында татарча куелган спектакль карап кайткан шикелле берничә көн хисләнеп йөрдем. Заманча алымнар, стиль, сценография, ут байлыгы, пантомима, пластика, артистлар уйнавы, музыка, барысы да кушылып, искиткеч нәтиҗә бирде, таң калдырды һәм ни гаҗәп, үтә заманча куелыш булса да, анда татар мохите бар иде. Ә «Умай»ның либреттосын укымасаң, гомумән, әсәр нәрсә турында икәнне аңлап булмый. Соңга калып кергән кеше буларак, либретто укырга кирәклеген белмәгән идем, шуңа күрә үземнең бай фантазиямне эшкә җигәргә туры килде. Кеше күп иде, ак яулыклы апалар, ханымнар, әфәнделәр... «Ал яулык, зәңгәр шәл...» дип аталгач, халык милли булыр дип уйлагандыр инде. Нәтиҗәдә, уңченче минутта, залда утыручылар әкренләп селкенә, «уффф, эххх» дигән тавышлар ишетелә башлады. Кыскасы, халык карап та, тыңлап та арыды. Мин үземнең визуалист икәнемне аңлап, шок хәлендә калдым. Сәхнәдә булган картина миңа берничек тә ошамый иде, түшәмнән аска төшерелгән ямьсез ванна да коткармады. 25 минут бер хәлдә торган тишекле стенага, татарчарак булсын диптер инде, эленгән шәл дә әллә ни үзгәртмәде. Шуңа күрә, опера булса да, игътибарны музыкага бик нык бирмичә карадым.

> Эстетик яктан да, креатив яктан да, режиссерлык гомумән бик сай. Күренешләр күңелсез. Фәкать өченче өлешендә генә ниндидер җанлану барлыкка килде. Карарга кызык түгел, тыңларга авыр.

Апам уйнаганга күрә генә, чәчкәләремне кысып, бу әйбер кайчан бетәр икән дип, түзеп, артистларны җәлләп утырдым. Алар тырышты инде, чөнки бүтәнчә ярамый. Булганны-булмаганны кысып чыгарып, җырлый алганнары җырлап, җырлый алмаганнары «опера» күрсәтеп, 1 сәг 20 минут буе мәш килделәр. Чынлыкта опера җырларлык, консерватория белемле бер генә артист бар анда. Ә бит опера – бик катлаулы һәм кыйммәтле жанр, аны теләсә кем башкара алмый. Опера артисты булыр өчен, җырчы ничә еллар укый, өйрәнә, сәхнәгә чыгып, бертуктаусыз бер сәгатьтән артык җырлый. Бу 3–4 минутлык бер җыр башкару гына түгел. Аларның үзенчәлеге дә, тавышны җиткерә белүе дә башка. Драма артистларыннан опера җырчылары ясаулары нәрсәгә кирәк булган икән, һич тә аңламыйм. Менә шушы «опера»га 3 миллион сум акча түктеләр инде. Күпме музыка язылган, оркестр һәм артистлар шуны тырышып өйрәнгән бит, берәр рәтле мюзикл, я музыкаль әсәр куйсалар, әйбәтрәк булыр иде дигән фикер калды. Нишләп яшь режиссерларга, Тинчурин артистларын, шул изге сәхнәне экспериментлар өчен шулай җәлләмичә бирәләр икән?.. Ичмасам, ул режиссерлар башта куярга өйрәнсеннәр иде... Артистларның күбесе бу әйбердә катнашырга теләмәде бит, ләкин уйнамыйсыз икән, театрдан китегез, дип әйттеләр аларга. Спектакль вакытында, кайбер тамашачылар, чыдамыйча, залдан чыгып китте. Театр өчен иң кадерлесе – тамашачы, ә аларның кабат килергә теләкләре булыр микән?

:: Тинчурин театры – синең өчен нинди җир ул? Һәм ул нинди юнәлештә үсәргә тиеш?

– Кайчандыр бу бинаны минем әти белән әни, күренекле шәхесләр, Мәскәүләрдә йөреп, сорапып, ялынып алган. Үзем күптән анда эшләмәсәм дә, бу театр өчен йөрәк әрни. Бу театр – минем өчен иң якын җир ул. Һәм аның потенциалы бай. Иң мөһиме, театрны ярата һәм артистларны хөрмәт итә торган режиссер кирәк!

:: Ярый әле киттем театрдан, дип уйлаганың бармы?

– Алай уйлаган чаклар күп булды. Чөнки режиссер белән бер дулкында булмасаң, анда эшләүдән мәгънә юк, гомерең заяга узар.

:: Алма агачыннан ерак төшми, диләр. Улларыгыз Сәләйман белән Йосыф сәнгатькә тартыламы? Аларның киләчәктә нинди һөнәр сайлавын теләр идегез?

– Малайларымда режиссерлык сәләте бар, үзем дә гаҗәпләнәм. Алар компьютер уеннарында, үз сценарийлары буенча уйнатып, шуны төшереп, видеороликлар ясарга яраталар. Нәрсә булып бетәр, күз күрер.

:: Ике малай өчен нинди әни булырга кирәк?

– Акыллы, тәртипле, чыдам. Үземдә андый сыйфатлар барын бар, әмма кайвакыт бетеп тә китә. Иң мөһиме балаларны ярату булырга тиеш, калганы баш бәласе түгел.

:: Менә сине мәдәният министры итеп куйдылар ди, иң беренче нәрсәне үзгәртер идең?

– Ооо, мәдәният министры, гомумән, булмас идем. Бик авыр, рәхмәтсез эш бит ул *(көлә)*.

:: Ләйсән, кайсы гына эшкә алынма, син – йөз процентка башкарып чыга торган кешеләрнең берсе. Шулай да, потенциалың тулысынча файдаланылмады кебек. Дөресме?

– Минем потенциал 40 процентка гына файдаланыла, күп эш эшләнмичә кала. Элегрәк ялкаулык, вакытында арт санга тартучы булмаганга эшләнми иде. Хәзер кайбер әйберләр хәтердән китә башлады.

:: Зур, грандиоз планнарың белән дә бүлешсәң иде.

– Юк, бүлешмим, кыстамагыз да. Алдан кычкырган күкенең башы авырта, ди. Вакыты җиткәч, ниятләрем барып чыккач кына сөйләрмен, Алла боерса.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ҖИР ЙОТМАГАН

(ХИКӘЯ)

< Дәвамы. Башы 15, 22 июль саннарында

-2-

Күктә каен утыны белән меңәрләгән мич якканнармыни, иртән үк кыздыра башлады. Бүлмәләр эсселәнмәсен дип, тәрәзәне япканда күршеләрнең ишегалдында эт өрде. Гаҗәп, хайван Гөлсем белән исәнләшә, аның өзек-өзек өрүе дә йомшак, аннан битәр койрыгын болгавы сәламләү билгесе кебек иде. Менә сиңа мә! Хуҗасыннан алда маэмай белән танышты хатын.

Кинәт ишек ачылып, баскычтан дүрт читле адәм төште дә кулындагы каеш белән эткә сыдырды. Хайван, чинап, читкә сикерде.

– Марш урамга! Пес итеп кер!

Гөлсем имәнеп китте. «Дүртчитле» күз алдында ябыга, яңаклары суырылып, муены нечкәрә иде. Коточкыч рәвештә тазарса да, хатын таныды аны, таныды! Уң җилкәсенә таш аскандай янтаеп атлавына хәтле аныкы!

Гөлсем капчык төсле идәнгә ишелде. Колакта зыңгылдаган исем... Ире ике генә мәртәбә әйтте аны. "Без Дамин белән – конкурентлар. Миңа яный, өченче кибет төзетсәң – иштерәм, ди». Туксанынчы хәтәр еллар. Көндәш эшкуарлар бер-берсен аямый. Һәр иртә ул Мөдәррисне тәрәзәдән карап озатып кала иде. Ире подъездан чыккан гына иде, каршысында ябык кына бәндә калыкты. Шул ук мизгелдә Мөдәррис талчыбык төсле җиргә бөгелде... Ә теге ябык адәм уңга янтаеп, тиз-тиз китеп барды. Урамга атылган хатын өстенә иелгәндә үлем белән тартышкан ире:

– Дамин, – диде.

Сулыш киселде...

Дөньяны кара пәрдә каплады...

Җир убылды...

Йөрәген телем-телем тураган фаҗиганең бердәнбер шаһиты Гөлсемнең гаризасын теркәделәр, әммә «эш» кузгатканда үтерүченең исеме язылмады, аңа «билгесез җинаятьче» дигән тамга сугылды. Шуңа күрә Даминны эзләп тә интекмәделәр. Соңыннан барысы да ачыкланды. Улы Илдар мәктәптә укый иде әле, аларга юлда сәләмә генә киемле бер абзый очрады.

– Мөдәрриснең хатыны бит син, сеңел, – диде ул, борынын тыңкышлатып. – Бума миндә, сеңел. Беркөн буылып үләрмен дим. Дару да булышмый. Иреңне Дамин йомдырды, сеңел. Нигә аны тотмадылар, нигә качырдылар? Туганы органнарда хезмәттә иде. Мин Дамин шоферы идем, каян белим мәкерле ниятен? Безнең ирләрчә разборка, тыкрыкта гына көт, диде. Каян белим, сеңел… – Абзый авызын очлатып, һава суырды. – Буа, зәхмәт.

Гөлсем, акылдан язгандай, аның күкрәген дөмбәсләде:

– Ник шул вакытта ук тикшерүчегә сөйләмәдең?! Ник, ник?!

– Курыктым, сеңел. Дамин – ерткычның ерткычы, үтерә иде мине дә.

...Аннан соң байтак сулар акты. Сәләмә киемле абзый, бәлки, чиреннән терелмичә, гөнаһлы җанын Аллаһка тапшыргандыр. Гөлсемгә дә саташуыннан туктарга кирәк. Өченче күршесе – бүтән кеше, бүтән. Каһәр суккан Даминның Казаннан эз суытуына биш былтыр.

Урамда мәхшәр купты. Этләр чинашты, аларны уздырып, Марсовна кычкырды:

– Фу, бетле! Фу!

Хатын терсәгенә таянып аякланды. Эчтәге ялкын басылмасмы дип, салкын су эчеп тынычланмакчы иде, ишек дөбердәде һәм күзе-башы акайган Марсовна бусагага ауды.

– Аллам, Аллам, үләм! Инфаркт! Тизрәк укол када, кызкай. Овчаркасын безнең тирәдә чаптыра, шартлатак. Этенең өстендә юк, шыр ялангач. Минекеләр ефәк камзулдан, аларның киемен селәгәйле авызы белән буяп уйный, бетле! Уйнатырмын менә, типтем каты гына. – «Эт анасы» залдагы диванга табан үрмәләде. – Җәтрәк бул, када укол!

Гөлсем:

– Кул-аякларыгызны кымшатасыз, иренегез күгәрмәгән, телегез бәйләнми, сез сау-сәламәт, – дисә дә, түрә ханым үзенекен тукыды:

– Үләм, дим ич! Инфаркт! Када! Уф, минем яхшылыгымны бәяләрсеңме икән, кызкай. Танышым Чау-чау токымлы көчек сата. Алтмыш биш мең! Ташлама белән. Җүп-җүн. Акчаңны әзерлә! Ялгыз башыңа бер иптәш, кызкай.

– Рәхмәт, юкка мәшәкатьләнмәгез, Минкия Марсовна. Мин ялгыз түгел, минем улым бар. Өйләнер, оныкларым туар, шулар белән юанырмын, Алла боерса.

– Малаең бар? Кайда ул?

– Аның үз фатиры.

– Хи-хи, хәерче кисәгеннән хәерче ярала. Кайда эшли улың?

– Прокуратурада, Минкия Марсовна.

– Хи-хи, ишегалды себерәмени?

– Ул – прокурор ярдәмчесе, Минкия апа.

Күршесенең мыскыллап чалшайган авызы турайды.

– Әтәч! Затлыдан затлы күршеләрем икән сез!

Бая гына «хәерче кисәге» Гөлсем затлыдан затлыга әйләнде.

– Каяле, матурым, әтиеңнең исемен кушып эндәшермен моннан ары. – Кинәт кенә «терелгән» «эт анасы» телефонына ябышты. – Номерыңны әйтче, сакларга куям. Син дә сакла. Бүгеннән туганнар кебек якынаябыз. Прокурор ярдәмчесе дисең, ә? Ай-яй, кәттә җиргә урнашкан улың, ай-яй. Минкия апа белән без ахирәтләр диярсең аңа. Шуны белте овчарканы аттырсын әле менә. Дамин пыжымласын әле менә.

Гөлсем көзге яфрак төсле бөрешә. Нинди Дамин ул? Җан кыючы теге бәндәме әллә? Юк ла, аны күптән җир йотарга тиеш иде.

– Нәрсә шымайдың? – диде Минкия. – Кечтеки генә гозеремне үтәмәсмени улың, ә?

Минкияне озаткач та ул тәрәзә буеннан китмәде. Пәрдәнең читеннән генә эләктереп, күрше ишегалдына караган саен йөрәк чәнечте. Исән... Җир йотмаган, чирканган... Әнә ишектән бүселде. Әнә чылбырдагы этенең сыртына каеш белән сыдырды:

– Живо, пес итеп кер!

Хайван авыртудан дүрт аягына чүкте. Урамда аны, мөгаен, тагын берәү рәнҗетер. «Балаларымны әүмәкләтсә, тимер таяк белән ботын сугып сындырам», – дип гайрәтләнгән Минкия акырды:

– Фу, бетле, фу!

Хатын кесәсендәге телефоннан Илдарга шылтыратмакчы иде, экранда бармагы «тайды». Йөрәктәге шаукымлы дулкын кулын калтырата. Ниһаять, «улым» сызыгына тиде бармак. Илдар – эшем кешесе, ләкин вакыты тыгыз булса да ул җавап бирергә тырыша иде.

– Авырдыңмы әллә, әни?

– Юу-ук. Өч авазлы бер сүз ике иҗеккә бүленде. – Улым, ачуланма, сабый йөрәге яраланмасын дип яшергән идем синнән. Әтиеңне Дамин атлы адәм көпә-көндез атып үтерде.

Чыбык очындагы Илдар:

– Беләм, – диде. – Хәтерлисеңме, мәктәп юлында бер абзый туктатты. Кечкенә, аңышмас дигәнсеңдер, әни, ә мин ул абзыйның һәр сүзен күңелемә беркеттем һәм ант иттем: үсәм, юрист һөнәренә укыйм, законнар өйрәнәм, шуннан соң ерткычны ауларга тотынам. Табам мин аны, табам да хөкемгә тарттырам, әни.

– Эзлисе юу-ук, ул безнең күршедә генә, улы-ым!

– Бер айдан командировкам төгәлләнә, син, зинһар, тынычлан, әни.

– Әтиеңне үтергән җәллад күршеңдә генә яшәгәндә ничек тынычланыйм, ди, Илдар?!

– Ә син ничек тә тынычлан, әни.

Улы әнисен юатып тагын нидер әйтте, тик колак шаулап саңгыраулаган Гөлсем соңгы киңәшен ишетмәде, аны эчтәге өермә бөтереп алып тәрәзәгә табан очырта иде.

Югыйсә якын барма тәрәзәгә! Карама кеше йортына, карама!

Ике «бала»сын кочаклаган «эт анасы» һаман овчарка белән көрәшә:

– Ышкылма балаларыма, пошел вон!

Җәллад ишегалдында иде, менә ул этен чакырды, менә тагын каеш хайванның сыртын каезлады. Бичара эт чинамады, ыңгырашты гына. Менә җәллад соры машинасын кабызды. Менә капкасы ябылды. Акылы кителгән Гөлсем, тәрәзәдән кубып, урамга чыкты. «Бетле»дән котылган «балалар» чирәмдә тәгәрәшә иде.

– Бирегә килче, Гөлсем Мансуровна. – Минкия аңа кул изәде. – Үләм, укол кадыйсыңмы әллә? Нервым кабарды.

– Ә сез тынычланыгыз.

Илдарның тынычлан дигәненә үртәлгән хатын үзе дә шул сүзне кабатлады.

– Һи, тынычланырсың монда. Бетле, нарасыйларым белән уйнамакчы. Әгәр улың аттырмаса, агу эчерәм, валлаһи.

– Аны хуҗасы җәберләгән генә җитмәгән, сез дә үчегәсез. Бетле дә түгел әле ул!

Минкия ирен читен кыйшайтып елмайды.

– Синеке дә дөрес, Гөлсем Мансуровна.

И бу ялагайлар дөньясы! Гади шәфкать туташы белән вакланмас кына идең, һай, вакландыра шул. Прокурор ярдәмчесенең анасы ла. Акны кара дисә дә, килешәсең. Аның каравы балчык изгән сыман турларында таптанган Солтанморат картка җенләнде «эт анасы»:

– Йөрмә син дә, эч пошырып!

Ә бабайда карчыгы «әкият» дип бетереп ташлаган хикәятенең чын икәнен исбатлау хәсрәте, ул шуңа, кытыкланып, Гөлсемнең килгәнен көтә иде. Ләкин хатын аңа илтифат итмәде, аның үзенеке куәтлерәк иде.

-3-

Улына хәбәр итеп ялгышты. Аждаһа белән газиз баласын көрәштерергәме соң инде, йә?! Закон, закон… Бөтен очракта да үтәләме ул?

Кырмавык төсле күңелгә ябышкан шик-шөбһәләрне Минкия көчәйтеп кенә җибәрде:

– Өч көн күренми.

– Кем?

Аның исемен ишетәсең киләмени, җүләр хатын? Әйдә ишет тә бәгыреңә кырык шырпы кадат.

Ахыры бар >

Шигърият

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ

МИН ӘЙТТЕМ...

...Стенага терәп
сорый Кирәк –
тамагы киң аның, Кирәкнең...
Рәсәй кешесе дә кеше кебек
бер яшәргә тиеш:
– МИН ӘЙТТЕМ!

...Тыелып торган чишмәләр күп иде,
рәхмәт, Заман,
ачтың, киңәйттең...
Калганнары миннән соңгыларның
Әйтер сүзен көтә:
– МИН ӘЙТТЕМ!

...Бер дә гаҗәп түгел яманлыкка
әйләнүе яхшы ниятнең...
Яманлыкның гына
яхшылыкка
әйләнүе булмас:
– МИН ӘЙТТЕМ!

...Үз яры бар хәтта тал-тирәкнең,
ник булмасын һәрбер йөрәкнең...
Эзләп,
табып,
югалтып ла кара –
син дә саргаерсың:
– МИН ӘЙТТЕМ!

...Еламаска өйрәтүең белән
шигырь язарга да өйрәттең...
Рәхмәт, язмыш,
илгә һәм халыкка
әйтер сүзле иттең:
– МИН ӘЙТТЕМ!

...Тарту безнең нәселдә юк иде,
ә мин, җүләр,
байтак көйрәттем...
Илне яклап көрәшмәгәннәргә
илне тарту хәрәм:
– МИН ӘЙТТЕМ!

КАЙТУЛАР

I

Туган җиргә кайтты егет,
Калды кинәт тукталып...
Монда үсте, ташны ташка
Бәрә-бәрә ут табып...

Аң-таң булып торды озак:
– Кайда чакмалы таулар?
Үр генә булган лабаса
Балачактагы таулар.

II

Аксакал кайтты иленә,
Сагынып авыл үрен...
Авыл үрендә булсын дип
Теләгән иде гүрен.

Кайда ул җилләнеп йөргән,
Күңелгә сеңгән үрләр?
Биек тау булган лабаса
Яшьлектә менгән үрләр.

САБАНТУЙ

Сабантуйларда да алга карый халык,
Көрәштерә башлый нәниләрдән алып.

Сөлгеләр тотыла, һәр авыл
Батырын күзәтә, билгеле...
Мәйдан күк кысыла йөрәкләр:
– Бирмә билеңне!
– Бирмә-ә-ә...

Дошманнар таптаса җиреңне,
Сорамый: «Син батыр идеңме?»
Мәйдан күк кысыла бар халык:
– Бирмә илеңне!
– Бирмә!

Вәсвәсәле фәлсәфә

✓ Мәченең ни өчен шалкан тартуы миңа аңлашылмый. Алдында – дошман, артында – ризык. Ә ул ни өчендер шалкан тарта.
✓ «Сырник» дигән ризыкта ник сыр юк?
✓ Ир-атлар булмаса, дөньяда 90% җинаять булмас иде. Хатын-кызлар булмаса, дөньяда 10% җинаять булмас иде, аннары ир-атлар ясаган 90%ы да бетәр иде.
✓ «Тиеш» һәм «мәҗбүр» сүзләре бу тормышта еш кына синонимнар булып чыга.
✓ Велосипед тәгәрмәче әйләнгәндә, аның эчендәге һавасы да әйләнә микән?
✓ Гаилә ул – хатыныңа бүләк иткән кәнфитләрне үзең ашап бетерү.
✓ Әйберне ничек итеп ике кешегә гадел бүләргә? Беренче кеше бүлә, икенче кеше сайлый.
✓ Салым ул – илдә яшәргә еллык подписка. Пенсия ул – кэшбек. Ә ана капиталы – яңа чакырып китергән катнашучы өчен бонус.
✓ Хәзер бушлай берни юк. Хәтта алданасың килсә дә, башта акча түләргә кирәк.

Әз-мәз мәзәк

Операда:
– Тавышланмагыз! Увертюра!
– Үзеңне бел!

* * *

Газ сатучы иң эре компаниянең җитәкчесенә сокланам мин. Аның кебек айга 50 млн сум хезмәт хакы алсам, икенче айны эшкә чыгарга мин үземдә көч таба алмас идем.

* * *

– Классташлар очрашуына барасыңмы?
– Юк, анда барырга мин тормышта әле бернинди дәрәҗәгә дә ирешмәдем.

* * *

«Син бераүгә дә берни тиеш түгел!» – диде миңа психолог. Бу консультациясе өчен мин аңа 5000 сум тиеш булдым.

* * *

Бер хатын-кыз урамда ялгыш егылып китә. Моны күргән ирләр көлә башлый. Кыз аягына баса да әйтеп куя: «Ярый әле ирләр күрмәде, оятка кала идем!»



Беләсең килсә

1 Язучы Иван Тургенев дустының хатынына гашыйк була. Һәм бу ханымны 40 ел яратып яши. Аның исеме:
а) Полина Влади;
б) Полина Виардо;
в) Полина Виагра.

2 Дилә Нигъмәтуллина Гөлназ Сафәровага элек кем иде?
а) авылдаш;
б) курсташ;
в) килендәш.

3 Татарстанда ничә төрле елан яши?
а) 4;
б) 6;
в) 8.

4 1863 елгы Надежда Горелко бу шәһәрдә туган иң беренче бала санала. Әмма берничә елдан соң аннан беренчелекне алалар. Ефросинья Сметанина аннан ике көнгә алданрак туган икән. Сүз нинди шәһәр турында?
а) Владимир;
б) Владикавказ;
в) Владивосток.

Җаваплар: 1. б); 2. в); 3. а); 4. в).

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Шамкай, Рабит, остаханә, Анатыш, Рамил, мут, Атилла, Кунут, агыш, Ермак, ягулык, Никулин, им, алама, Лия, тар, Миладил, әннәги, бас, селәгәй, мөртәт, Нина, Онегин, ак, Иттифак, си, үкчә, Гарәфә, Әлмәндәр, зина, АН, Гумилев, Фюнес.

Вертикаль: Шәрәфиев, Илгиз, алимент, лит, ранг, Анапа, Әнисә, ау, ким, Гафифә, йодрык, Камилә, Әлки, уку, йокы, атаман, Шәле, Итури, тегү, Халит, кода, җан, ми, әни, Назлыгөл, Өнсә, рәт, Илнар, Алия, Башмагым, тәбә, Ык, Агата, Такташ, Харис, Кәрәкәс.

Сәхифәне Данил САФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 16052 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 308

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+